До приезда Садри Максуди из Парижа в августе 1906г. именно Акчура был единственным политиком европейского уровня среди татар. В августе 1906г. на III Всероссийском мусульманском съезде Гаспринский предложил его кандидатуру на должность заместителя муфтия по юридическим вопросам. Несмотря на скромное название должности, ее обладатель должен был сконцентрировать в своих руках все отношения с государственными властями, а также со светской политической элитой. В 1906г. на III Всероссийском мусульманском съезде Акчура был избран членом секретариата съезда, а затем членом ЦК партии «Иттифак аль-муслимин».

Уже в начале 1906г. Юсуф был арестован на 40 дней под предлогом авторства социал-демократических прокламаций. Власти не реагировали на заявление самого Акчуры, что он придерживается либеральных убеждений, и на ручательство за политика наиболее влиятельных членов татарской общины Казани. Действительной же причиной было нежелание властей видеть его среди депутатов I Государственной Думы. Роспуск II Государственной Думы в июне 1907г. обозначил окончание поры либеральных надежд. Для кипучей деятельности Акчуры просто не оставалось места. Перед отъездом в августе 1908г. из Казани в Стамбул Юсуф Акчура выпустил книгу «Юченче июнь вакыйгаи мюэсэффэсе» (В связи событиями третьего июня. – Оренбург, 1907), где оценил события 3 июня 1907 г. как государственный переворот, нарушающий движение России по пути европейских государств. Он утверждал, что III Государственная Дума не в состоянии, или почти не в состоянии, принять необходимые для страны законы. Таким образом, народ в России не может участвовать в издании законов и управлении государством, и утверждение о конституционном характере российской монархии является фикцией.

Ю. Акчуру больше привлекали фабриканты Баку, Оренбурга и Казани. В них он видел будущее российских мусульман. В 1912г. в статье «Тюркский мир» Ю.Акчура писал, что «в современном тюркском мире возникает новая социальная сила – буржуазия (средний класс). Богатый средний класс крупных торговцев, промышленников и владельцев шахт в Баку, Оренбурге и Казани – основных центрах тюрок Севера и Азербайджана – служит здесь примером. Средний класс является националистическим. Его экономические интересы требуют прогресса и развития национальной идеи и чувств. Очень быстро теоретики (идеологи) национализма группируются вокруг буржуазии Казани, Баку и Оренбурга». Если Стамбул является нервным центром и мозгом тюркского мира, то

тюрки Казани выполняют в этом мире функции центра торговли и образования, экономически объединяя тюркский мир.

В 1911г. в Стамбуле Акчура стал редактором журнала «Тюрк йорду» («Тюркский мир»). В 1913г. этот журнал среди татар был наиболее популярным зарубежным периодическим изданием. Он имел до 50 подписчиков только в Казани.

В годы бесконечных войн Акчура, как преподаватель, отдавал всего себя молодежи. В дни поражения Османской империи в I Балканской войне (1912г.) он в университетской аудитории просил прощения у студентов за то, что не научил их жить по образцам процветающих наций Европы.

В 1915г. в Казани вышел в свет сборник, посвященный Шихабутдину Марджани. Акчура объявляет Марджани великим предшественником начавшегося движения «таджаддуд» (реформации). Акчура тем самым строит своеобразную предысторию джадидизма, задавая тон для будущей либеральной тюркской историографии. Сам Акчура не сомневался, что по прошествии половины века в тюркском-мусульманском мире произойдет религиозно-мыслительная революция – «таджаддуд».

В 1917–1919гг. Акчура последний раз побывал в России (включая Казань и Уфу) как представитель турецкого Красного Полумесяца и не принимал участия в политической деятельности. В 1919г. он уже настолько чувствовал себя турецким гражданином, что отказался от предложения занять пост главы дипломатического ведомства намечавшейся «Федерации юго-восточных мусульманских областей».

В кемалистской Турции он был профессором Стамбульского и Анкарского университетов, в 1931 г. создал и возглавил Турецкое историческое общество, в 1932г. он руководил работой Первого Турецкого исторического конгресса, являлся депутатом Великого Национального Собрания, советником президента Турции Ататюрка по вопросам культуры и науки.

Если Рашид Ибрагим только обозначил контуры татарского политического движения, то Акчура заложил его прочные основы. Одновременно его можно назвать первым татарским политологом, социологом и политическим историком. Его концепция общетюркской истории, происхождения и развития тюркского единства до сих пор остается боевым знаменем всех тюркских народов мира. В 1904г. во время пребывания в родном ауле Зюя Баш под Симбирском он написал работу «Три политические системы» («Уч тарз-и сеясят»), про которую говорят, что она сыграла такую же роль в истории тюркизма, как «Манифест Коммунистической партии» в истории марксизма. Работы Юсуфа Акчуры создали татарскую политическую науку и публицистику, не уступавшую лучшим европейским образцам.

# ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН КОНТЕКСТЫНДА БӨЕК ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕНЕҢ ПЕДАГОГИК МИРАСЫ

**Гаделшина Рузия Зөфәр кызы**
*МБГББУ «М.М.Мансуров исемендәге*
*Зур Кукмара урта мәктәбе»*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Татар халкының мең елларга сузылган тормышында тупланган тәҗрибәсе, гадәтләре, кешене шәхес итүче сыйфатлары, бай тарихы, тәрбия зиннәтләре бар. Шуларга мөрәҗәгать итү тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген көчәйтә. Нәрсә соң ул тәрбия? дигән сорауга иң гади һәм аңлаешлы җавап мондый булыр иде кебек: тәрбия – ул яшь, психологик, физик үзенчәлекләрне исәпкә алып, халыкның тәрбия традицияләренә нигезләнеп, балаларны һәрьяклы үсеш алган шәхес итеп формалаштыру.

Дәрестән тыш эшчәнлек программасына татар халкының гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәр, халык авыз иҗаты үрнәкләрен чагылдырган материаллар тупладым. Җырлы-биюле уеннар, табышмак, мәкальләр өйрәнүне максат итеп куйдым. Халык йолалары, традицияләре, фольклор аркылы бала шәхесендә олыларга карата хөрмәт,табигатькә сакчыл караш, үзара хөрмәт, ярдәмләшү тәрбияләнә. Укучылар тәртибендә үзгәрешләр сизелә башлый. Бу инде аларның аңлы рәвештә үзләренең сәламәтлекләренә карата уңай мөнәсәбәт тудыра. Чыннан да, без яшь буынны үзебезнең урынга әзерләргә, өлкәннәргә булган иң күркәм сыйфатларны аларда тәрбияләргә тиешбез.

Укытучы – белем бирүче генә түгел, чын мәгънәсендә тәрбияче дә. Ул яшь кешенең эчке дөньясын, сәләтен, әхлакый сыйфатларын, психологик үзенчәлекләрен күздә тотып эшләргә бурычлы.

5 – 9 нчы сыйныф өчен дәрестән тыш эш программасы татар халык авыз иҗаты төрләрен,аларның яшь үзенчәлегенә туры килерлек үрнәкләрен үз эченә ала. Бу темалар балаларның телне үзләштерү дәрәҗәсенә туры килерлек итеп, метапредмет бәйләнешләрне, уку процессындагы логик эзлеклелекне искә алып сайланган һәм сәгатьләргә бүленгән.

Халык авыз иҗаты баланы сәнгать дөньясына җәлеп итү, халыкның традицияләре белән таныштыру өчен иң кулай материал булып кына калмый, образлы фикерләү үстерү, эстетик кыйммәтләргә уңай караш тудыруда да зур ярдәм итә. Туган халкы авыз иҗаты әсәрләре баланы бишектән алып озатып килсә, күрше халык иҗаты үрнәкләре аңа дөньяны танып белергә, толерант шәхес булып формалашырга зур ярдәм итә.

Белем бирү процессын халыкның күпьеллык традицияләренә нигезләнеп кору бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрдән санала, чөнки халык җырлары, экиятләре, уеннары, мәкаль һәм әйтемнәре, гореф-гадәтләре баланың рухи-эстетик үсешендә төп рольне уйный, тормышны аңлауда һәм аңа яраклашуда зур ярдәм итә.

Программаның максаты: халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәкләрен өйрәнеп, укучыларның интеллект дәрәҗәсен үстерү, тормышка яраклашкан (социальләшкән) шәхес тәрбияләү.

Бу максатка бәйле рәвештә түбәндәге бурычлар куелды:

– татар халык авыз иҗаты тарихы, жанрлары, халыкның милли киемнәре белән танышу

– халык традицияләренә, костюмына, милли мирасына кызыксыну хисләре, хөрмәт уяту.

– халкыбызның йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә кызыкыну тәрбияләү.

– балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.

Программаны тормышка ашыру барышында төркемдә һәм коллективта эшләү формалары кулланыла. Бу формалар аралашу сәләтен үстерү өчен файдалы.

Эш барышында 5 – 9 нчы сыйныф укучыларынын яшь үзенчәлекләренә туры килә торган төрләргә зуррак урын бирү күздә тотыла. Бу – уеннар, җырлар, милли кием элементлары белән танышу, табышмаклар өйрәнү, халкыбызның гореф-гадәтләрен өйрәнүгә бәйле.

## ЮСУФ АКЧУРА: ЕЩЕ ОДИН ДЕЯТЕЛЬ ТАТАРСКОГО ПРОИСХОЖДЕНИЯ

**Гареева Рида Талгатовна**
*МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №89*
*с углубленным изучением отдельных предметов» г. Казани*
*Учитель русского языка и литературы*

Юсуф Акчура известный татарский общественно-политический деятель, ученый, один из основоположников политического тюркизма, чей вклад в формирование татарской и турецкой наций был огромен.

Ю. Акчура выходец из известного татарского рода, один из предков Ю. Акчуры, князь Адаш, был близким другом русского царя Ивана IV. Акчурины владели множеством текстильных фабрик в Казани, Симбир-

ске и других местах. Львиная доля тканей для царской армии производилась именно на фабриках Акчуриных. После смерти деда Сулеймана отец Юсуфа, Хасан, получил в наследство 3 ткацкие фабрики: в Симбирске, в Лаховке и в деревне Зюя. Хасан женился на Бибикамарбану, дочери известного казанского фабриканта Абдурашида Юнусова. У этих семей были неплохие отношения с русскими властями. Известно, что когда царь Николай I приехал в Казань, он остановился в доме Юнусовых.

Ю. Акчура родился в 1876 году. Через 2 года неожиданно умирает его отец. А в 1882 году во время поездки в Казань сани, в которых ехала мать, опрокинулись, и она получила нервное потрясение. С тех пор она часто болела, врачи советовали матери жить в теплом климате, поэтому Ю. Акчура и его мать в 1883 году уехали в Стамбул. Большим событием в жизни Юсуфа в 1889- 1890 годах стало путешествие на родину, в г. Симбирск, потом в Казань, а летом и весной они с матерью съездили в Уфу, в деревню Девлекен на реке Деме, в г. Касимово, Нижний Новгород.

В этом путешествии юноша вел дневник, наблюдал жизнь разных тюркских народов, отмечая их зависимое положение в России. Юсуф еще несколько раз посещал родные края, где познакомился с Каюмом Насыри, Галимджаном Баруди, генералом Шамилем, сыном вождя горцев шейха Шамиля. Во время своих путешествий Ю. Акчура часто останавливался в Крыму, в Бахчисарае у И. Гаспринского, который был женат на одной из родственниц Юсуфа. Своим интересом к тюркологии юноша был обязан своему дяде Ибрагим-бею, жившему в Симбирске и взявшему управление фабриками отца Юсуфа в свои руки. Юсуф пользовался его богатейшей библиотекой.

В 1897 году Акчура был арестован за свои взгляды, и по решению султана его отправляют в пожизненную ссылку в г. Триполи (Ливия). Благодаря переговорам младотурок с султаном Абдул-хамидом II он был переведен на вольное поселение. Потом он перебрался в Париж. В 1899-1903 годах Ю. Акчура учится в свободной Школе политических наук и одновременно посещает лекции Высшей школы прикладных наук Сорбонского университета. В Париже он изучал политические науки, философию, социологию, историю и филологию. В Школе политических наук слушал лекции известных ученых. Сорель, Рено и Бутми, которые были сторонниками идеи «здорового» национализма сформировали соответствующее мировоззрение и твердые убеждения у Юсуфа Акчуры, и придали их мыслям четкую национальную направленность. Наблюдения о жизни тюркских народов, полученные во время путешествий, участие в

дискуссиях в Школе и благодаря знаниям, Юсуф начинал задумываться о месте национализма и тюркизма в политической сфере.

В 1903 году Ю. Акчура заканчивает учебу. Его дипломная диссертация называлась «Исследование по истории государственных институтов Османской империи». Проблему улучшения структуры государства автор предлагает рассматривать: а) с позиций интересов одного отдельно взятого народа империи; б) с позиций интересов различных народов; в) с позиций интересов султана и людей, стоящих у власти; г) с позиций интересов государства. Ю. Акчура пишет о том, что если отдельным народам не дать автономии, то они добьются полной независимости с помощью оружия и тогда окончательно отделятся от империи. В заключение автор приходит к мысли, что для сохранения Османского государства в существующих границах оно должно превратиться в государство федерального типа. Ю. Акчура тесную связь с движением младотурок, представители которого жили в эмиграции в Париже. В эти же годы Ю. Акчура печатается в газетах. Он пишет с рационалистических позиций, верит в силу прогресса и просвещения и открыто выражает свою ненависть к деспотическому режиму султана.

В 1902 году в Париж из Казани приезжает Садри Максуди. Он поступает на юридический факультет Сорбоннского университета, знакомится с Ю. Акчурой, и с тех пор они становятся друзьями и единомышленниками на всю жизнь. Живя в Париже, Ю. Акчура переписывался с И. Гаспринским. И вот однажды Акчура получил письмо от него, где было написано о том, что весной 1903 года исполнится 20 лет со дня выхода в свет первого номера газеты «Тарджеман». И два татарских студента, Юсуф и Садри, пишут 27-страничный текст о необходимости проведения торжественного юбилея газеты в Бахчисарае, затем распечатывают его в ста экземплярах и рассылают его ста самым видным и авторитетным деятелям и лидерам тюркских и мусульманских народов. Этот юбилей, действительно, оказался торжественным и многолюдным. Вот что писал С. Максуди о значении этого юбилея: «Это торжество стало, по сути, первым съездом российских тюрок. На этом собрании впервые говорили о национальных проблемах, о путях сохранения национальной культуры, о мерах, которые нужно предпринять против политики русификации».

После окончания учебы в Париже Ю. Акчура приезжает в Россию, и с 1904 года начинается его казанский период жизни, который длится до октября 1908 года. В Казани он начинает преподавать в медресе «Мухаммадия», там же активно способствовал становлению реформаторского движения среди шакирдов. С осени 1905 года в Казани начинает выходить

первая татарская газета «Казан мухбире», редактором был Ю.Акчура. Кроме того, он играет громадную роль в зарождении и организации татарского национального движения, в формировании Всероссийской мусульманской партии «Иттифак аль-муслимин» («Союз мусульман»), костяк которой составляла татарская буржуазия и интеллигенция. Но в России Ю. Акчура не сумел развернуть свою политическую деятельность. Пытаясь помешать его избранию в I Государственную думу, царские власти его арестовали. В 1908 году Ю. Акчура уезжает в Стамбул. После провозглашения Турции республикой он избирается депутатом Милли меджлиса Турции, затем работает в качестве профессора Стамбульского университета и советника президента Турции Кемаля Ата-тюрка по вопросам культуры и политики. В 1931 году под руководством Ататюрка он участвует в создании Турецкого исторического общества, избирается его председателем. А в 1932 году по поручению президента он руководит работой I Турецкого исторического конгресса. Его женой была Сельма-ханум. У них в 1924 году родилась дочь Улькен, которая сейчас живет в Стамбуле, в 1927 году родился сын Тугрул, умер в 1984году. Ю. Акчура умер 11 марта 1935 года в Стамбуле. Его имя носит одна из центральных улиц Анкары, столицы Турции.

## Э.ШӘРИФУЛЛИНАНЫҢ «ЗАКИРӘ ТИРӘГЕ» ХИКӘЯСЕ ҺӘМ Р.ФӘХРЕТДИН НӘСИХӘТЛӘРЕ

**Гарифуллина Дилбәр Рафак кызы**
*Татарстан Республикасы*
*Мөслим муниципаль районы муниципаль*
*бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*«Кубәк урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*Югары категорияле туган тел укытучысы*

Бүгенге шау-шулы заманда тәрбия, әдәп-әхлак мәсьәләләре күпләребезне борчый. Җәмгыятебез рухи яктан ярлылана бара. Яшь буын арасында әйләнә-тирәдәгеләрнең шатлыкларына һәм хәсрәтләренә игътибарсызлык, матурлыктан ләззәт алып яшәмәү, ямьсезлекне күреп йөз чөерү урынына битарафлык күрсәтү гадәти күренешкә әверелә бара. Менә шундый авыр шартларда бездә таяныр кыйблабызны табу ихтыяҗы туды. Ә бердәнбер юл, таяну ноктасы – әхлак тәрбиясе бирү. Әхлак тәрбиясен исә без әдәбият дәресләре һәм дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында алып барабыз.

«Тәрбиядән яраладыр тәрбия». Сүземне Р.Фәхреддиннең яшь буынны тәрбияләүдә әйтеп калдырган гыйбарәсеннән башлыйм: «Кеше булу өчен, – ди ул, – гыйлем белән күркәм холык кирәктер, һәм дә боларны бер-берләреннән аеру дөрес булмас».

Бүгенге әдәбият дәресләренең бурычы – бала күңеленә үтеп кереп, аңарда күркәм сыйфатлар тәрбияләү. Бу дәресләр шулай ук укучыларны уйландырырга тиеш. Без балаларны маңгай күзе белән генә түгел, күңел күзе белән дә «укырга» өйрәтергә тиешбез. Әсәрне укып чыкканнан соң, укучы борчыла икән, әсәрнең тәэсир көче шунда. Минем эш принцибым да шундый.

Бүгенге көндә «Нәрсә укырга?» дигән сорауны ачыклау бик әһәмиятле. Балаларның кызыксыну даирәсен исәпкә алып, татар әдәбиятында хәзерге чорның һәм тормышның актуаль проблемаларын яктырткан әсәрләргә мөрәҗәгать итү кирәк. «Бәхет ачкычы» дигән дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында әсәрләр шушы максаттан һәм укучыларның теләкләре буенча сайлап алына.

Кеше кайчан бәхетле? Бәхеткә юллар ураумы? Бәхетне каян табарга? Әхлакый кыйммәтләрне каян эзләргә? Укучыларга аларны ничек тәкъдим итәргә? «Мәйдан» журналын актарып утырганда, күзем Э.Шәрифуллинаның «Закирә тирәге» хикәясенә төште. Әсәрне зур кызыксыну белән укып чыктым. Укыдым да уйга калдым. Мин эзләгән сорауларга җавап шушы әсәрдә иде. Мин әлеге әсәрнең тәрбияви кыйммәтенә игътибар иттем һәм эзләнү эшемне башладым.

Максатым: Э.Шәрифуллинаның «Закирә тирәге» хикәясендә әхлакый кыйммәтләрне билгеләү һәм аларны Р.Фәхреддин нәсихәтләре яссылыгында карау.

Бурычлар: Э.Шәрифуллинаның «Закирә тирәге» хикәясенең төп фикерен үзләштерү. Әсәрдәге төп фикерләрне Р.Фәхреддин нәсыйхәтләре белән дәлилләү.

Өйрәнү объекты һәм предметы – Э.Шәрифуллинаның «Закирә тирәге» хикәясе.

Тикшерену өчен әдәби анализ һәм бәяләмә алымнарын файдаландым.

«Уяныгыз, ямьйсы бар бу дөньяның яраларын!..» Нинди яралар хакында сүз бара икән диярсез... Э.Шәрифуллинаның «Закирә тирәге» хикәясенең төпкелләрендә ул яралар.

«Закирә тирәге» хикәясендә төрле заман һәм халыклар өчен уртак, кызыклы һәм әһәмиятле булган мәңгелек тема ул – мәхәббәт һәм нәфрәт, тугрылык һәм хыянәт, ышаныч һәм өмет. Әсәр материалында куелган

үткен каршылыкларда ачылучы мәсьәлә – хатын – кыз бәхете, ягъни шәхси бәхет мәсьәләсе.

Проблеманы барлыкка килү сәбәпләрен эзләдем. Әһәмияте буенча төп фактларга ачыклык керттем. Хикәянең төп кыйммәтен ачыкладым. «Закирә тирәге» хикәясенең асылы аның идеясендә, нинди уй-фикерләр үткәрүендә, нәрсәгә инанырга чакыруында. Әсәрдән алган тормыш сабакларын Р.Фәхреддин нәсихәтләре яссылыгына салдым:

1. Бәхет пыяла кебек, сакламасаң – уала. Закирә тирәге әсәрдә зур роль уйный. Ул – гомер буе тату, үрнәк булып чөкердәшеп яшәгән Закир белән Закирәгә, аларның олы Мәхәббәтләренә үзләре исән чагында ук табигать куйган һәйкәл. Мәхәббәт – изге хис. Аны таптарга ярамый. Мәхәббәт булган җирдә бәхет һәрчак янәшә йөри. Хатын-кыз–гаилә учагын саклаучы. Ул гаиләне уңай дулкында алып барырга бурычлы. Солтания шуңа омтыла да. Татар хатын-кызларын тыйнаклык бизи, диләр. Бу Солтанияга хас сыйфат. Тик менә шул сабырлыгын, тыйнаклыгын ире таптап үткән. Фикеремне Р. Фәхреддин нәсихәтләре белән дәлиллим. Аның «Олуглар вә бөекләр өчен» («Әхлак гыйлеме» ннән) дигән хезмәтендә болай диелә: «Ирләр бозык булмасалар, хатыннар фәрештәләр кебек яхшы булырлар иде» («Ир әдәпләре»).

«Хатын әдәпләре» ндә исә аның тарафыннан мондый фикер әйтелә: «Хатыннарны мәхәббәтле күрсәтәчәк нәрсә – чибәрлек түгел, холыктыр. Күп хатыннар булыр ки: чибәрлекләре камил булмаган хәлдә, һәркем каршында теләнгән булып күренерләр. Вә хөрмәт белән сөйләнерләр. Шуның өчен гүзәл холыклы вә миһербанлы булыгыз!», «Ачулы йөзле булмагыз, ачу галәмәтләре белән һичкемгә күренмәгез, ачу вакытында сөйләшмәгез, хосусан башкаларга җавап бирүдән сакланыгыз, чөнки ачу вакытында җавап бирү сәбәпле ачу көчләнер»**.**

Р.Фәхреддин бу сүзләре дә урынлы: «Кызым! Дөнья һәрчак нигъмәт белән генә тулып тормый, агулары да, чәнечкеләре дә очраштыра. Ике арагызда каршылык туса – кызма! Ирең никадәр ачуланса да, каршы сүз әйтмә! Ирләр каршында иң яхшы хатын – юл бирүче хатын» («Гакыллы бер хатынның нәсыйхәте»)

2. Уйлап эшлә! Ахырдан үкенерлек булмасын! Якты хыяллар белән башланган яшьлек, тормышта хыянәткә урын булырга тиеш түгел. Һәркемнең бәхетле булырга хакы бар. Шул исәптән Зөләйханың да, Солтанияның да, Сиринә белән Айдарның да. Тик ул бәхет кеше бәхетенә уралып кына төзелмәсен!

Бу фикерләрне Риза Фәхреддиннең «Әһле гыяль» (Өй җәмәгате) китабыннан алынган нәсыйхәтләр белән дәлиллим: Тиң булу (Ир белән ха-

тын бер-берсенә тиң булса гына, алар арасында берлек һәм дуслык хөкем сөрер. Дөньяның рәхәте – байлык түгел, ә күңел тынычлыгындадыр). Өйләнешү, никахлашу. (Хатын курчак түгел, һәрчак уйнап-көлеп тормас. Хатын кием түгел, бүген киеп, иртәгә салынмас. Хатын хайван түгел, ошаса – асралып, ошамаса – базарда сатылмас. Хатын хезмәтче дә түгел, яхшы хезмәт итсә – асралып, хезмәт итә белмәсә – куып җибәрелмәс. Хатын – тормыш юлдашы, гомерлек иптәштер). Таш йөрәкләр, кара күңелләр күркәм холык алдында йомшарырлар, буйсынырлар. Дошман һәм дусны ризалату өчен, күркәм холыктан үткен корал дөньяда юктыр.

3. Мәхәббәтне намус, сафлык, җаваплылык белән бәйләп караган кеше генә бәхетле була. Э.Шәрифуллина әсәрендә тормыш чынбарлыгын ачып салып, яшәү рәвешебез хакында уйланырга мәҗбүр итә. Бәхетле гаиләдә балалар да бәхетле була. Сиринәнең күңелендәге гарасатны әтисе генә туктата ала. Кыз әтисенең бу хыянәтен кичерерме? Әтисе белән әнисе арасындагы пыскып утырган кисәү дөрләп кабынырмы? Шушы сораулар ачык килеш кала. Гаиләдә җаваплылык турында әйтергә тели автор.

Менә шул тормыш сабаклары бирүе белән әдибәнең бу әсәре Р.Фәхреддин нәсыйхәтләре белән аваздаш: «Изге шәригать буенча, ир – хатынны үзенә иптәшлек өчен кабул итеп алучыдыр. Ата вә анасыннан, кардәш вә кабиләсеннән, туган-үскән җирләреннән аерылып килгән хатынын олылап, хөрмәт итеп торучыдыр. Ир үзенең хатынын мәшәкатьләрдән, төрле зәхмәтләрдән саклар. Хатынына нәсыйхәтләр бирер вә аны шәфкать канаты астында тәрбия кылыр. Юк-бар сүзләр белән хатынын борчымас, аңа карата ягымлы, мәрхәмәтле булыр, авыр эшләр йөкләмәс...» («Ир»). Гаилә бәхете, хикәядәгечә, тормыш киртәләре һәм сынаулар аша килә. Гомер юлыннан җитәкләп чыгарлык, күңел яраларын «бәйләрлек», ике йөрәккә маяк булырлык мәхәббәт тә кирәк. Без киләчәк турында уйларга, гаилә тормышына аңлы караштa булырга тиешбез. Әдәби әсәр укучыга рухи чистарыну алып килергә тиеш. Бу чистарынуга бер генә нәтиҗәгә китерә. Язылмаган әхлакый кыйммәтләрне аңлауга. Әхлак белән әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвештә булыр», – дип юкка гына әйтмәгәндер Р.Фәхреддин.

# БӨЕК МӘГЪРИФӘТЧЕ КАЮМ НАСЫЙРИ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ТӘРБИЯ БИРҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Гильфанова Венера Җәүдәт кызы**
*Казан шәһәре «25 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Башлангыч сыйныфлар укытучысы*

Бөтен гомерен яраткан халкына хезмәт итүгә багышлаган, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре шактый күп. Болар арасында иң лаеклы урыннарның берсен, бик хаклы рәвештә, бөек галим, мәгърифәтче Каюм Насыйри алып тора.

К.Насыйри милләтне агарту, аң-белемле, һөнәрле итү, әхлакый тәрбияләү, уку-укыту системасын үзгәртеп кору, һәм, гомумән, татар тормышын һәрьяклап яңарту идеяләре белән сугарылган мәгърифәтчелек идеологиясе белән шөгыльләнә. Мәгърифәтченең әсәрләрендә төп проблема булып уку-укыту һәм тәрбия мәсьәләләре тора. Бу хезмәтләр яшь буынның тәрбияле, белемле һәм сәламәт булып үсүен күз алдында тотып язылганнар. К. Насыйри яшьләрдә туган илгә мәхәббәт, кыюлык, батырлык, тапкырлык, хезмәт сөючәнлек, дөреслек, тугрылык, күркәмлек кебек әхлак сыйфатларын тәрбияләргә киңәш иткән.

Эшемнең максаты: күренекле мәгърифәтчебез К. Насыйри хезмәтләрендә тәрбия бирү мәсьәләләрен анализлау һәм, бүгенге көн таләпләренә туры китереп, үземнең укыту-тәрбия эшемдә куллану.

Бурычлар: күренекле галим һәм мәгърифәтченең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру, аның тәрбия бирүгә багышланган хезмәтләренә тукталу.

Эш барышында мин бөек мәгърифәтченең тәрбия мәсьәләренә багышланган хезмәтләре белән таныштым, тикшеренү һәм анализ методларын кулландым.

Яшь буынны тәрбияләү мәсьәләләре, гаилә белән мәктәп, тәрбия белән хокук мөнәсәбәтләре элек-электән кешелек дөньясының игътибар үзәгендә булган. Әхлак тәрбиясе бирү дигәндә, без бай рухи сыйфатлар, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен булдыру, аларны камилләштерүне күз алдында тотабыз. Бүгенге көндә яшь буынга әхлак тәрбиясе бирү укытучы эшендә бик актуаль, иң кирәкле юнәлешләрнең берсе булып тора.

К. Насыйри укыту-тәрбия турындагы хезмәтләрендә халык тарихын язу өчен материал бирә, укыту-тәрбия өлкәсендә хәзерге көндә дә зур игътибарга лаек фикерләр әйтә. Ул – күп еллар укытучылык итү тәҗрибәсенә нигезләнгән теоретик хезмәтләр калдырган педагог. Аның әдәби һәм педа-

гогик әсәрләре халык педагогикасына нигезләнеп язылган, халыкчанлык белән сугарылган. Бу аның халык өчен әһәмиятле мәсьәләләр күтәрүендә һәм китапларында халык иҗатына киң урын бирүендә күренә.

К. Насыйриның әхлак һәм укыту-тәрбия мәсьәләләренә караган «Кырык бакча» (1880), «Балаларга тәгълим бирмәк» (1882), «Китап-әт-тәрбия» (1891) кебек бай эчтәлекле хезмәтләре хәзер дә бик заманча яңгырый.

Әдипнең әхлак, тәрбия, педагогика өлкәсендәге фикерләре дә гаять әһәмиятле. Ул зур тәҗрибәле укытучы-практик кына түгел, шул бай тәҗрибә нигезендә теоретик хезмәтләр язган педагог та.

Кешенең уңай характеры бары тик хезмәт процессында гына формалашканын мәгърифәтче бик яхшы аңлаган. Шуңа күрә әхлак тәрбиясенең төп нигезе итеп галим хезмәт тәрбиясен алган.

К. Насыйриның әхлак һәм укыту-тәрбия мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрендә халкыбызның тормыш-көнкүреше, үзара мөнәсәбәте, эчке кичерешләре, тәрбия тәҗрибәсе тасвирлана. Бөек галим укытучылык эшчәнлегендә халыкның педагогик мирасына, тәрбиядә халыкчанлыкка һәм гуманлылыкка зур өстенлек бирә һәм бу аның төп педагогик принцибы булып әверелә. Чөнки ул халык тәрбиясенең кешене белемле һәм әдәп-әхлаклы итеп үстерүгә гаять зур өлеш кертүен дәлилли, шуңа күрә татар халык педагогикасын һәрьяклап өйрәнүгә күп көч куя. Кыскасы, аның хезмәтләре татар халкының тәрбия тәҗрибәсенә нигезләнеп иҗат ителә.

К. Насыйри белем-тәрбия бирүнең берлеген һәм дәвамчанлыгын, әхлакый тәрбиянең мөһимлеген, акыл һәм тәҗрибәнең тыгыз бәйләнештә торуын күрсәтә. Аның фикеренчә, ата-ана, мөгаллим шәхси яктан балага тәрбиялелекнең үрнәге булып торырга тиеш.

Шунысы мөһим: К. Насыйри тәрбияви сабакларын еш кына гыйбрәтле мисаллар, җанлы сюжетлар ярдәмендә бирә. Бу исә үгет-нәсыйхәтләрнең үтемлелеген, тәэсирлелеген тагын да арттыра.

Һәрберебезнең изге бурычы – балаларны белемле итү генә түгел, тәрбияле, әхлаклы итү. Күренекле мәгърифәтче, бөек галим К. Насыйриның педагогик карашлары хәзер дә актуаль булып кала. Аның күпкырлы һәм бай мирасын укучыларга өйрәтү, педагогик эшчәнлегемдә куллану – минем бурычым.

Мин бөек галимебезнең иҗади мирасына тирән хөрмәт белән карыйм. Нәкъ менә тыйнаклыгы, итагатьлелеге, фикер-карашларының ачыклыгы белән замандашларын да сокландыра алган мәгърифәтче К. Насыйриның бай мирасы бүгенге буын балаларын тәрбияләү өчен бик аваздаш, мөһим чыганак булып тора. Аның хезмәтләре белән балаларны гына түгел, бүгенге көн әти-әниләрен дә таныштырырга кирәк дип саныйм.

# ТАТАР МӘГАРИФЕНЕҢ ГҮЗӘЛ ЭНҖЕЛӘРЕ

**Гыймадиева Гүзәл Ильдус кызы**
*Казан шәһәре Киров районының*
*«4нче Гимназия-интернаты»*
*муниципаль автономияле гомуми*
*белем учреждениясе*
*Педагог-китапханәче*

Казан шәһәре Киров районында урнашкан 4-нче гимназия-интернатның тәрбия эшчәнлегендә 12 ел дәверендә «Мәгърифәт йолдыз-лыгы» проекты эшләп килә. Бу проектның авторы һәм җитәкчесе буларак эйтә алам: аның барлыкка килүе очраклы түгел, гимназиябездә кызлар гына белем ала. Безгә татар мәгарифе, аеруча, хатын-кызлар мәгарифе тарихы бик тә кызыклы һәм әз өйрәнелгән булып тоелды.

Проектның максатлары: халкыбызның тарихын өйрәнү, саклау, үстерү, укучыларда милләткә һәм туган илгә карата ихтирам тәрбияләү, милли үзаң формалаштыру. Татар мәгърифәтчесе, галим Ризаэддин Фәхреддин болай дигән: «Яхшы тәрбияле, киң белемле кызлар гына чын «милләт аналары» булып җитешәчәк һәм киләчәктә милләтне алга алып барырлык шәхесләр тәрбияләчәк». Безнең проектыбызның эшчәнлеге бу фикерне дәлилләп, укучы кызларыбызны белемле, әхлакле, гүзәл холы-клы булып тәрбияләргә ярдәм итә. Укучы кызлар белән архивларда, му-зейларда булып, китаплар һәм журналларда аларга багышланган чыгана-клар эзләп, күп кенә материаллар туплыйбыз.

Фатыйха Аитова мәктәбе укыту программасыннан алып, шул вакыт-тагы уку әсбапларына таянып, тарихи торгызылган дәресләр әзерлибез: **Әхлак, тыйб (медицина), кул эшләре, хисаб һ.б. Каюм Насыйриның «Әнмүнәҗ» дәреслеге буенча татар теле грамматикасы дәресен әзерләп күрсәттек.** Проектыбыз кысаларында без 10 ел фәнни-гамәли конференцияләр уздырабыз. Бүгенге көндә алар халык-ара дәрәҗәсендә үткәрелә. Чараларыбызны Бөтендонья Татар конгрессы, Казан Федераль Университеты филология факультеты белән берлектә әзерлибез. Гасыр башында кызлар өчен мәктәпләр ачыла башлаганга 100 елдан артык ва-кыт узуы сәбәпле, без татар мәгърифәтчеләренең мирасларын барлап, параллельләр уздырып, киләчәгебез турында уйланабыз.. Конференция кысаларында шәһәр күләмендә «Асылташ» укучы кызлар конкурсы уздырабыз.

Безнең бай рухи мирасыбыз, мәгърур матбугатыбыз һәм бер үк ва-кытта хатын-кызларыбыз хәрәкәтендә мәңге җуелмас эз калдырган

шәхесләребез бар. Тик халкыбызның гаять бай тарихлы булуын, ни кызганыч, бары соңгы елларда гына аңлый башладык шул. Тарихыбызның, андагы шәхесләрнең, шул исәптән зыялы кызларыбызның да тормыш юлларын гаять дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуы нинди аяныч нәтиҗәләргә китерде.

Татарларның укымышлы кызларын да, аларның туган халкына күрсәткән хезмәтләрен дә һич онытырга ярамый.

Хәйриячелек – кешелек уйлап тапкан, диннәр хуплаган, хәтта кушкан изге гамәлләрнең берсе. Бәлки, бу дөрестер дә. Хәйриячелек һич тә афишалап башкарыла торган эш түгел. Татар мәкале дә «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык күрмәсә, балык күрер» ди. Урамга чыгып кычкыргач, гамәлнең изгелегеннән бернәрсә дә калмый ич.

Изге күңелле мәгърифәтче хатын-кызларыбыз татар кызларына беренче җәдид мәктәпләрен ачканнар. Мәктәпләр бары тик байлар һәм мәхәллә халкы хисабына гына яши алганнар. Халыкның аң-белемгә омтылышын күреп, татар байлары яңа мәктәп-мәдрәсә ачу өчен акча кызганмаганнар. Мәктәпләрдә дин белеменнән тыш дөньяви фәннәрне дә (математика, физика, химия, география, тарих, чит телләр) укытканнар. Татар рухи мәдәниятен үстерү юлында берничә буыннар дәвамында хезмәт күрсәткән аерым шәхесләр, бөек шагыйрьләребез, язучыларыбыз, галимнәребез, тарихчылар, хәтта аерым нәселләр бар. Халыкны ан-белемле итүдә күренекле шәхесләребез Гаяз Исхакый, Шиһабетдин Мәрҗәни, Фәхреддиновлар нәселе, Йосыф Акчура, Исмагыйль Гаспралы, Апанаевлар, Яушевлар, Юнусовлар, фабрикант Акчуриннар, кебек зур сәнәгатьчеләр булганнар. Алар мәчетләр төзүгә, мәктәпләр, мәдрәсәләр ачуга йөзәрләгән мең акчаларын химая иткәннәр, уннарча уку йортларын үз акчаларына яшәткәннәр, аеруча сәләтле шәкертләрне чит ил уку йортларына югары белем, тәҗрибә туплау өчен җибәргәннәр.

Кызлар язмышы – милләт язмышы. Мәгърифәт учагы булган безнең уку йортыбыз (Казан шәһәре 4 нче гимназия-интернаты) да иң беренче буларак хөрмәтле беренче президентыбыз Минтимер Шарипович Шаймиевнең уй-нияте белән булдырылды. Аның изге ниятен тормышка ашыруда фидакяр хәйриячеләрнең шәхси матди-мәгънәви ярдәмнәренең өлешләре зур булды. Гимназиябездә конкурслар үтеп, төрле төбәкләрдән килгән, сәләтле кызлар гына белем ала.

Төрле елларда бу уку йортын тәмамлап, кызларыбыз югару уку йортларында белем алып, туган йортларына әйләнеп кайткан кебек, гимназиягә балаларны укытырга кайталар. Аларның төп бурычлары, гомумән мон-

да эшләүче хәрберебезнеңдә, – мәгърифәтле, мәдәниятле, әхлакле, үз милләтенең мәнфәгатьләрен кайгыртучы кыз-балалар тәрбияләргә.

Татар кызы дигәч тә, аның тарихтагы урыны искә төшә. Бик борынгыдан затлы нәсел кызлары татарның милли байлыгы булган.. татар кызына өйләнү башка халыклар арасында да зур мәртәбә саналган.. Дөньякүләм билгеле шәхесләрнең йә әбиләре йә әниләре юкка гына татар түгел. Димәк бар халыклар да таныган бик мөхим сыйфатларыбыз бар, һәм без аларны югалтмыйча сакларга тиешбез.

## КАЮМ НАСЫЙРИ – БӨЕК МӘГЪРИФӘТЧЕ

**Григорьева Сөмбел Мөхәмәтфагиз кызы**
*Мөслим муниципаль районы Яңа Усы төп белем бирү мәктәбе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Бөтен гомере буе халыкка фидакарьләрчә хезмәт кылган, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре шактый күп: Утыз Имәни, Габдулла Тукай, Шиһабеддин Мәрҗани, Риза Фәхреддин, Гаяз Исхакый, һ. б. Болар арасында иң мөхтәрәм урыннарның берсен Каюм Насыйри, гасыр башындагыча әйткәндә, Каюм баба алып тора. 77 яшендә вафат булган бу игелекле зат ярты гасырдан артык, алны-ялны белмичә, милләткә хезмәт итә. Ул дауламый да, шауламый да, дәгъвалар да куймый, бәхәс-конфликтка да керми – халыкның нәкъ үзе кебек – меңләгән кыенлыкларны сабыр гына, тавышсыз-тынсыз гына җиңә-җиңә эшли дә эшли, эшли дә эшли. Аның өчен байлык та, дан-шөһрәт тә мөһим түгел. Каюм бабаны тырышлыгы белән мәсәлләргә кергән кырмыска белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Әмма кырмыска кышын ял итә, үз «җыйганын» үзе ашый. Каюм бабаның исә җәе генә түгел, кышы да урак өсте кебек. Аның «җыйганы», аның хезмәт җимеше – барыннан да элек, башкалар өчен, милләтнең киләчәге өчен.

К. Насыйриның беренче фәнни хезмәтләре үк Петербург галимнәре тарафыннан уңай бәя ала. Ул этнография материалларын җыю өчен, гыйлми җәмгыятьләрнең утырышларында каралган программалар белән дә тәэмин ителә. К. Насыйри картлык көннәренә кадәр Казан университеты янындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең актив члены булып эшләвен дәвам иттерә: татар халык әдәбияты һәм гомумән культурасы буенча материаллар җыеп, җәмгыять карамагына тапшыра бара, җәмгыятьнең утырышларында докладлар ясый. «Волжеский вестник»

газетасы 1895 ел, 21 нче февральдә чыккан 45 нче санында Насыйриның шундый әдәби-гыйлми хезмәтләре турында «Казан татарларның халык әдәбияты памятниклары» исеме белән бер мәкалә урнаштыра. Без анда түбәндәге юлларны укыйбыз: «Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең соңгы утырышында Казан шәһәрендә торучы Габделкаюм Насыйров тарафыннан татар җырлары, табышмаклары җыентыгы куелды. Татар халык әдәбияты әсәрләреннән булган бу җыентык, бу көнгә билгеле җыентыклар арасында, киң рәвештә төзелгән булып тора».

Димәк, К. Насыйриның иҗат эшчәнлегенә шул чордагы вакытлы матбугатта тәнкыйтьчеләр дә игътибар иткәннәр.

К. Насыйри фән эшлекләләре белән генә түгел, бәлки типография эшчеләре белән дә якын бәйләнештә булган. Моны университет типографиясе наборщикларының язган хатлары ачык күрсәтә.

К. Насыйриның китаплары басылып чыгу реакцион көчләрне аңарга каршы куйса, икенче яктан, ул заманының алдынгы кешеләре тарафыннан теләктәшлек тә таба. Аның китапларын сорап, Казан губернасыннән генә түгел, Россиядә татарлар яшәгән бик күп урыннардан бер-бер артлы хатлар килеп тора.

Шулай итеп, К. Насыйриның күпьяклы әдәби хезмәте, халык интересларын күздә тоткан мәгърифәтчелек эшчәнлеге көннән-көн үсә барган.

К. Насыйри гомерен, бөтенләй дип әйтерлек, Казанда яшәп, иҗат өстендә уздыра. Берничә мәртәбә агасы Габделхәт янына Мәскәүгә бара, соңрак Уфада һәм Оренбургта була. Бу сәяхәтләреннән тыш, һәр язны дип әйтерлек, туган авылы Югары Шырданга кайта торган була. Шунда Зөя һәм гомумән Тау ягындагы авылларга чыгып, андагы тарихи истәлекләрне-памятникларны тикшереп-карап йөрергә яраткан. Ул бик күп иске кабер ташлардагы язмаларны җентекләп укыган, халыкның үз авызыннан җырлар һәм гомумән фольклор материалларын җыйган.

Язу-сызу, акыл хезмәте белән бергә, К. Насыйри физик эш белән дә шөгыльләнгән. Аның китап төпләү, көзге ясау, крахмал, лак, электричество ярдәмендә әйберләр көмешләү һәм слесарьлык эшләрендә дә осталыгы булган. «Һаман утырып язу ялыктыра, каннар оеша, мин һәр көн бер-ике сәгать эшләп, бу кораллар белән үземә кирәкле әйберләрне ясыйм», – дип әйтә торган була. Аның бүлмәсендә кыру станогы һ.б кирәк-яраклар тора.

Дәреслекләренә карталар сызу, рәсемнәр төшерү эшләрен дә үзе башкара. Ул бигрәк тә агачтан төрле әйберләр ясарга яраткан, кирәк булган әйберләрнең барсын да үзе эшләгән.

К. Насыйри халык медицинасыннан файдаланган, төрле үләннәр белән дәваланган, физик хезмәт белән шөгыльләнгән. Шуның нәтиҗәсе буларак, бөтенләй дип әйтерлек ятып авырмаган. Бары тик гомеренең соңгы елларында гына аякларын җиңелчә паралич суга һәм ул үзен-үзе электр белән дәвалый, гел хәрәкәттә булырга тырыша. Нәтиҗәдә, аяклар яңадан язылып, йөрерлек хәлгә килә.

К. Насыйри гыйльми-әдәби эшчәнлеген мәдрәсәдә уку елларында ук башлый. Аның үзе шәп вакытта гына да татар һәм рус телләрендә төрле зурлыктагы 40 лап китабы дөнья күрә. Болар арасында хәтта 600 биткә җиткәннәре дә бар.

Каюм баба китапларын күздән кичергәч, аны берүзе берничә фәнне укыткан «олуг мөгаллим, милләт педагогы» дип атарга мөмкин булыр иде. Аның укучылары – бөтен татар дөньясы. Каюм баба әйтерсең гомер буе тырыша-тырыша сабак бирә, үз халкын белемле, тәрбияле итәргә омтыла.

Тел – укыту, тәрбия бирүнең, милли үзаңны үстерүнең төп предметы. Нәкъ менә шуңа күрә дә «олуг мөгаллим» төп игътибарын телгә юнәлтә. К. Насыйри язган китапларның шактый өлеше татар телен һәм аны өйрәнү турында. Аның иң беренче хезмәте – «Нәхү китабы», ягъни татар теле синтаксисы. Текстлар татар һәм рус телендә бирелгән.

«Татар теле ул – урам теле, ломовойлар теле, әдәби гыйльми тел булырга сәләте юк аның», дигән карашлар яшәгән заманда, К. Насыйри халкыбызның туган телен кайнар яклап чыкты: «Ялган, яла бу! Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел. Бүтән телләрдән бер дә ким түгел, эшләмәгәнлек сәбәпле генә ул шулай артта калган», – дигән ялкынлы фикерләре белән эш алып барды. Татар теленең фән теле була алуын, моңа аның тулы хакы һәм мөмкинлекләре барлыгын исбат итте. К. Насыйри, телебезне гыйльми һәм гамәли яктан өйрәнеп, татар лингвистик фәнен тудыруга үзеннән зур өлеш кертте.

Әмма ул моның белән генә чикләнмичә, китапларын татарча язып, төрек, гарәп, рус, фарсы телләреннән күп кенә ядкярләрне тәрҗемә итеп, туган телебезнең мөмкинлекләрен тагын да арттырды, аны тагын да камилләштерә, баета төште. Хәлбуки, бер канаты белән талпынып, оча алмаган кош кебек, татар теле дә шушы бер тармагы, бер канаты белән генә югары күтәрелә алмас иде. К. Насыйри туган телнең киек канатын да үстерү һәм ныгытуны бергә алып бара. Икенче канаты исә – төрле фәннәрдән дәреслекләрне татар телендә язу, терминнарны татарча эшләү, орфографияне яңарту була.

К. Насыйри күпкырлы, энциклопедик. Аның хезмәтләре татар хал-кын белемле, тәрбияле итүдә үзенә күрә бер мәктәп, университет бул-ды. Татарның милли үзаңын, рухи хәтерен үстерүдә Каюм бабаның эшчәнлеге искиткеч зур.

Бөтен гомерен безнең халкыбызны агартып, аңа культура хезмәте, әдәби хезмәт күрсәтүгә багышлаган өлкән агабыз – бөек рус халкы ярдәмендә татар халкының да бәхетле тормышка ирешүенә чын күңелдән ышанган, татар балаларын, беренче буларак, русча укыту эшенә җиң сызганып керешеп, кагылу- сүгелүләргә, эзәрлекләүләргә карамастан, армый – талмый эшләгән К. Насыйринең хезмәтләре зур игътибар белән өйрәнелә, хөрмәт белән искә алына. Аның халыкларыбыз арасында дуслык, туганлык тойгыларын тәрбияләү өчен гади генә итеп әйткән сүзләре бүген дә көчле яңгырыйлар. Капитализмның авыр шартларында татарлар арасында прогресс һәм демократия өчен көрәш башлаган К. Насыйри исеме – бүген илебезнең иң күренекле кешеләре рәтендә урын алды.

## ЯКТАШЫМ БУЛГАН МӘГЪРИФӘТЧЕ ГАЛИМ – КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТЕЛ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Закирова Дания Минулла кызы**
*Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы*
*«Усман Әлмеев исемендәге Акъегет төп гомуми*
*белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет*
*гомуми белем бирү учреждениесе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Һәр халыкның тарихи үсешендә тирән эз калдырган данлы уллары, кешелек бәхете өчен көрәшкә зур өлеш керткән галим һәм әдипләре була. Каюм Насыйри – татар халкынын әнә шундый олы хөрмәтенә лаек булган күренекле мәгърифәтче галим. Ярты гасырдан артык, алны-ялны белмичә, К. Насыйри милләткә хезмәт итә, үз халкын белемле, тәрбияле итәргә омтыла. Татар халкының бөек улы Каюм Насыйридан бүгенге буынга кадәрге ара бер гасыр белән үлчәнә. Галәм тарихының шушы мизгелендә фән дөньясында гаять зур ачышлар ясалып, моңа кадәр күз алдына да китерүе мөмкин булмаган фантастик ыргылыш ясала. Дөньякүләм әһәмияткә тиң ачыш һәм уйлап табуларның һәркайсында, теориядә һәм гамәлдә булмасын, татар галимнәренең дә өлеше зур. Тел – укыту, тәрбия бирүнең милли үзаңны үстерүнең төп предметы.

Нәкъ менә шуңа күрә дә «олуг мөгаллим» төп игътибарын телгә юнәлтә. Каюм Насыйриның иң зур хезмәтләреннән берсе – аның тел өлкәсендәге эшчәнлеге. Бу өлкәдә ул бик катлаулы һәм күп яклы хезмәтләр башкара. Ул татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, шуңа хакы һәм сәләте барлыгын исбат иткән. Аны практик һәм фәнни эшкәртү юлында гаять кыю һәм зур эшчәнлек күрсәткән. Каюм Насыйри тел гыйлемендә шулкадәр күп кирәкле эшләрне башкарган ки, бу өлкәдә ул кагылмаган, хезмәт күрсәтмәгән бер генә тармак та юк дисәк, ялгышмабыз. Татар теленең ике томлы аңлатмалы сүзлеген («Ләһҗәи татари», 1895) беренче башлап ул төзегән һәм татар теленең никадәр бай икәнен күрсәткән. Аның бу сүзлеге бүгенге көндә дә зур фәнни хезмәт буларак кулланыла. Бу сүзлекләрдә еш очрый торган гарәп, фарсы сүзләренә аңлатма бирелгән, татар теленең бәхәсле мәсьәләләре күтәрелгән, сүзләренең килеп чыгышы чагылдырылган. Русча – татарча һәм татарча – русча сүзлекләрне төзеп, бастырып чыгарган. Математика, география һәм табигать фәннәре буенча киң массага аңлаешлы терминнар булдыру өстендә дә эшләгән. Дөрес һәм матур язу кагыйдәләрен күрсәткән беренче кулланманы («Кавагыйде китабәт», 1892) ул биргән. Татар теленең фәнни грамматикасын («Әнмүзәҗ», 1895) төзүгә дә нигезне Каюм Насыйри салган. Ул бу китабында беренче тапкыр авазларга классификация ясап, аларны 10 сузык авазга, 29 тартык авазга бүлеп күрсәтә, рус терминологиясендә кулланылган теш, тамак, аңкау, борын һ.б. терминнарны файдаланган. Аның бу хезмәтләре хәзер дә әле үзләренең тарихи әһәмиятләрен һәм фәнни кыйммәтләрен югалтмаганнар. Шул ук вакытта ул рус телен үзләштерү, рус китапларыннан файдалану өчен беренче чиратта кирәк булган уку китапларын булдыру өстендә эшләгән. Ул рус, татар грамматикаларында булган якынлыкларны, аерымлыкларны, үзенчәлекләрне өйрәнә һәм аларны укучыларына төшендерә барган. К. Насыйри керткән бу яңалык хәзерге көндә дә, балаларга икенче бер телне өйрәткәндә, уңышлы методларның берсе булып санала.

Каюм Насыйри татар теленең байлыгын рус теле белән чагыштырып карый. Рус матур әдәбиятында булган бай сурәтләү чараларын – эпитетларны татар сузләре белән уңышлы тәржемә итә. Мәсәлән, рус һәм татар телләрендәге иркәләү һәм кечерәйтү исемнәрен үзара чагыштыру өчен ул И. А. Крыловның түбәндәге шигъри юлларын китерә:

«Голубушка, как хороша!
Ну что за шейка, что за глазки!
Рассказывать, так, право, сказки!
Какие перушки! какой носок!

И, верно, ангельский быть должен голосок!»

Һәм шул юлларны:

«Һай күгәрчен генәм, ниндәен һәйбәт!

Кара анның муен гынасын, кара анның күз генәсен!...

Ниндәен нәфис анның йон гынасы!

Ниндәен матур анның борын гынасы!

Дәхи фәрештә тавышы кебек микән анның тавыш кынасы!» – дип тәрҗемә итә. Шуның белән Каюм Насыйри тел байлыгының төп чыганагы халык авыз иҗатында булуын күрсәтеп үткән.

Каюм Насыйриның тел турындагы карашларына бөек рус галиме һәм беренче рус грамматикасын төзүче Ломоносов хезмәтләренең шактый гына йогынтысы бар. Ломоносов:« рус теле... үзенең киңлеге, үзенең байлыгы белән... Европаның бөтен телләреннән бөек ул», -дигән булса, Каюм Насыйри да рус телен Россиядәге барлык телләрнең атасы һәм патшасы дип күрсәтә, аны яхшылап өйрәнергә һәм анның бай хәзинәләре белән файдаланырга чакыра. Әгәр дә Ломоносов, грамматиканың әһәмиятен күрсәтеп, аңарга югары бәя биргән булса, Каюм Насыйри да үзенең «Әнмүзәҗ»ендә «этимология – белемнәрнең анасы, грамматика-атасы», дип китерә. «Бу ике гыйлемне укып белмәктән фарыз шулдыр ки, сөйләшкәндә вә язганда телне хатадан сакламактыр. Бу ике фәнне белмәктән күп фәннәр вә күп гыйлемнәр туадыр», – ди.

Шул рәвешчә, Каюм Насыйри Ломоносов үрнәгендә тел гыйлеме буенча гаять әһәмиятле һәм кирәкле фәнни эшләр башкара, гомумхалык сөйләме нигезендә үсә башлаган татар демократик әдәби теленең нигез ташларын сала.

Мәгърифәтче Каюм Насыйриның тел өлкәсендәге хезмәтләренең тарихи кыйммәте зур. Чөнки Каюм Насыйри, татар укымышлыларыннан беренче буларак, гомумхалыкка аңлаешлы әдәби тел кирәклеген яклап чыккан, татар әдәби теленең сүзлек составын баету һәм грамматикасын фәнни нигездә үстерү мәсьәләләренә зур игътибар биргән. Менә болар барысы да Каюм Насыйриның тел өлкәсендәге эшчәнлегенең тарихи әһәмиятләрен билгелиләр, анның үз заманы өчен гаять кирәкле һәм прогрессив эшчәнлек алып барганлыгын күрсәтәләр.

Каюм Насыйри, татар культурасы тарихында беренче буларак, буржуаз жаргонга каршы көрәш башлаган. Ул татар теленең сүзлек составын чистартуга зур әһәмият биргән, гарәп – фарсы сүзләрен татар һәм рус теле сүзләре белән алыштыруны яклап чыккан. Төрки телләргә ияреп, «бар» сүзен «вар» дип, «кирәк» сүзен «кәрәк» дип язучыларны кискен тәнкыйть иткән. Каюм Насыйри мондый карашларга протест белдереп,

түбәндәге фикерләрне әйтеп чыга: «Ялган, яла бу! Без – татарлар, теле-без – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул. Бүтән телләрдән бер дә ким түгел».

Каюм Насыйри татар телендә фәнни терминология булдыра. Ул бу юлда да гаять кыю тәҗрибәләр ясый һәм зур нәтиҗәләргә ирешә, беренче чиратта гарәпчәдән алынып йөртелгән терминнар урынына татар сүзләрен термин итеп беркетү юлын тота. Арифметика буенча «Хисаплык» исеме белән язган дәреслегенең сүз башында Каюм Насыйри үзенең теләкләрен түбәндәгечә аңлатып биргән:

«Хисаплык» дигән китабыбызда истилах сүзләре өчен мөмкин кадәр телебездәге сүзләрне сайладык. Мәсәлән, «Хисаплык» дидек. Бу гәрчә гарәпчә сүз булса да, аны белмәгән кеше юктыр. Бу «Хисаплык» дигәнебез «гыйльме хисап» дигән сүз булсын. Вә янә «сан» дидек – гарәп телендә «исеме гадәд» дигән сүз урынына булсын. Вә янә гыйльме хисапның бер кагыйдәсен «жыю» дип әйттек, гарәпчә «җәмгы» дип әйтәләр».

Шул рәвешчә аңлатып бара торгач, Каюм Насыйри арифметикадагы дүрт гамәл мәсьәләләрен чишүгә бәйләнешле барлык төшенчәләрне дә татарча исемләп чыга. Шулардан сан, бүлү, сумма, калдык, бүлгеч, елеш һәм башкалар хәзерге көндә дә шул ук төшенчәдә йөртеләләр.

Геометрия һәм география дәреслекләрен язганда да Каюм Насыйри шул принцибыннан чыгып эш итә. «Үз телебезгә килешә торган сүзләрне табып, җәграфия терминнарын белдердем», – ди.

Алардан элекке китаплардагы киң күпчелеккә аңлаешсыз терминнар урынына татар теленнән ала. Мәсәлән: төн ягы, төшлек тарафы, кояш батышы тарафы, атау, ярты атау, ут тавы, елга, диңгез, тамак һәм башкалар. Бу терминнарны буржуаз язучылар Каюм Насыйридан соң да әле гарәпчә йөртергә аз тырышмыйлар. Ләкин алар, гомумхалык теленнән читкә киткәннәре өчен, берсе дә халык сөйләменә кереп китә алмыйлар.

Гомумхалык теленә таянып эш иткән Каюм Насыйри принцибы җиңеп чыга, ул кертә башлаган терминнар аныклана һәм камилләшә бара. Материкларны һәм аерым илләрнең исемнәрен Каюм Насыйри рус әдәби телендә йөртелгәнчә биреп килде: Европа, Азия, Африка, Америка, Англия, Бельгия, Голландия, Германия, Швейцария, Норвегия, Швеция, Греция һәм башкалар.

Гомумхалык өчен чыгарылган календарьларында Каюм Насыйри терминнар мәсьәләсендә тагын да кыюрак адым атлый:посылка, перевод, бандероль, пакет, почта, почтальон һ.б кебек почта-телеграф терминнарны; министерство, сенат, департамент кебек идарәгә бәйләнешле терминнары; барометр, термометр, манометр, телескоп, фотография,

литография, кебек техник терминнарны; артиллерия, полковник, капитан һ.б кебек хәрби терминнарны рус әдәбиятында кулланылганча ала. Болар Каюм Насыйриның халыкка якын торуын һәм терминология мәсьәләсендә прогрессив карашны яклаучы галим булуын күрсәтәләр. 1960-1970 елларда рус алынмаларының кирәклектән артык кулланылуы тыела башлый. Сөйләм һәм тел культурасының рус алынмалары исәбенә бозылуы татар теленең яшәеше мәсьәләсен дә көн тәртибенә китереп куйды. Үзгәртеп кору чорында күп кенә журналистлар, кыйбер галимнәр татар телен чистартабыз дип, гарәп-фарсы алынмаларына кире кайту турында сөйли башладылар, газета-журнал битләрендә гади халыкка аңлашылмый торган сүзләр, терминнар күренә башлады. Интернациональ сүзләрдән баш тартып, татарча сүзләр ясап карау омтылышлары булды: прогрессны-алгарыш, физический-физик урынына тәнви, предпринимательлек урынына-эш итү, симтом урынына авыру билгеләре, отпор урынына-типке кебек сүзләрне тәкъдим итеп карадылар, әмма бу сүзләр урнашып, халыклашып китмәделәр.

XX йөз башында татар телчесе Г.Нугайбәк «Төрлек» дигән морфология яза һәм анда бер генә алынма сүз дә кулланылмый. 1912 елда «Сагынмалык» китабында ул үзенең максатын болай дип күрсәтә: «Ана теле, татар теле! Мин сине сөям, җир йөзендәге барлык телләрдән артык күрәм. Үз сүзең белән бар теләкне дә аңлатырлык чагыңны беләсем килә, арага катнашканчүп-чарны, төпләре-тамырлары белән йолкып ташлап, алар урынына чын татарча гына сүзләр ишетәсем килә». Мин моның белән килешәм.

Әмма иҗтимагый тормыш белән тыгыз бәйләнгән, халыклашкан һәм киң кулланыш тапкан алынмаларны чыгарып ташлау мөмкин түгел. Әгәр халык аларны үзенеке иткән икән бернинди законнар, карарлар беән ул сүзләрне куллanудан тыеп булмый. Алынмаларга мөнәсәбәт мәсьәләсен һәр очракта конкрет хәл итәргә кирәк. Әмма бер нәрсә бәхәссез: телнең үзендә кирәкле сүз була торып, аның урынына алынма сүз куллану бөтенләй урынсыз.

Хәзерге татар-рус икетеллелеге шартларында тел, сөләм культурасы, милли телнең чисталыгы мәсьәләләре үзәктә тора. Кирәксезгә рус сүзләре кулланып сөйләшү әдәпсезлек, тәртипсезлек билгесе икәнен истән чыгармаска кирәк.

Каюм Насыйри тәрҗемә принциплары турында да күп уйлаган. Ул, бер телдән икенче телгә тәрҗемә итүнең гаять җаваплы булуын тирәннән аңлап, аңа иҗат эше итеп караган. Каюм Насыйри,һәр телнең үзенең әдәби үзенчәлекләре барлыгын истә тотып, шул үзенчәлекләрне һәм

нечкәлекләрне искә алып эш итәргә чакыра. Каюм Насыйри үзе берничә телне теоретик өйрәнгән һәм практик үзләштергән кеше. Ул гарәп, фарсы, төрек, борынгы үзбәк телләрен һәм бигрәк тә, беренче чиратта, рус телен яхшы белгән. Шуның белән бергә, ул һәр телнең үзенчәлегенә, эчке законнарына нык игътибар биреп эш иткән. Бу тармакта да Каюм Насыйрига, беренче чиратта, аның гомумхалык телен һәм халык авыз иҗатын тирәннән белеп файдалануы зур ярдәм иткән. «Петербург - каменный город, всем городам начальник» дигән рус җөмләсен татарчага тәрҗемә иткәндә ул аны «Петербург каласы таш кала, һәммә калаларга башкала» дигән бер татар җырын китерү белән тәрҗемә итә һәм шуның ярдәмендә мәгънәне тулырак, җөмләне образлырак бирүгә ирешә.

Шул рәвешчә, Каюм Насыйри хәзерге татар әдәби теленең нигез ташларын саклаучы була. Ләкин аны камилләштереп өлгерә алмый. Фәнни нигезләрен дөрес билгеләгән хәлдә, күп очракларда үзе дә әле иске традицияләрдә язуын дәвам иттергән. Ул бу кимчелекләрен, ачык карашлы галим буларак, үзе дә сизгән.

Башка милләт мәгърифәтчеләре шикелле үк, Каюм Насыйри да ана теле аша халыкка аң-белем бирүне күтәреп чыккан. Ул татар халкы мәдәниятенең артка калуын туган телгә әһәмият бирмәүдә күргән.

Бала өчен ана теле-аңлаешлы, иң якын тел. «Кеше үз теләге белән гарәп, фарсы, рус телләрен үзләштерә ала, ләкин үз телен белергә тиеш... Кеше...үзенең туган телен кагыйдәсез дә белер һәм һич тә ялгыш әйтмәс һәм хата сөйләмәс. Ләкин башка телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кагыйдәләрен белү кирәк». К.Насыйри үз телен белмичә белемле кеше булуны күз алдына да китерә алмаган.

Каюм Насыйриның балаларны ана телендә укыту таләбе белән чыгыш ясавы ул чор өчен прогрессив һәм революцион адым булган. Татар теле белем бирү чарасы, әдәби-гыйльми тел булсын өчен аның нигезләрен эшкәртергә, грамматик һәм лексик үзенчәлекләрен өйрәнергә кирәк була. Менә шуңа күрә дә татар теле белеменә нигез салу эшенә беренчеләрдән булып, Каюм Насыйри алына.

Каюм Насыйри, татар телен игътибар белән өйрәнеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килгән: «Әгәр дә без игътибар белән үзебезнең телебезне өйрәнсәк, аның сүзләр күләме, атамалар, гомумән, төзелеше буенча гарәп, фарсы телләреннән ким түгеллеген, кайбер яктан, бигрәк тә фигыльләр өлкәсендә баерак та булуын күрербез», – дигән.

Ул татар телендә укучылар өчен берничә дәреслек яза. 1892 елда дөрес язу һәм орфография кагыйдәләрен үз эченә алган «Кагыйдәләр китабы» басылып чыга. Бу хезмәтендә ул: «Һәрбер культуралы кешенең

ике төрле теле була: шуларның берсе – анасыннан сөт имгән вакытта өйрәнгән тел, икенчесе – укытучыдан укыганда-гыйлем һәм фән терминнары белән ачылган тел... » – дип яза. Күргәнебезчә, Каюм Насыйри фәнни төшенчәләргә, терминнарга зур игътибар биргән, тел, әдәбият һәм башка фән тармаклары буенча фәнни терминология булдыруга зур хезмәт куйган.

Каюм Насыйриның тел өлкәсендәге эшчәнлеге хәзерге көндә дә актуаль. 1960-1970 елларда рус алынмаларының артык кулланылуы тоела башлый. Сөйләм һәм тел культурасының рус алынмалары исәбенә бозылуы татар теленең яшәеше мәсьәләсен дә көн тәртибенә китереп куйды.

Республикабызда «Телләр турында» закон кабул ителгәннән соң, фәнни һәм уку-укыту әдәбиятында барлык сүзләрне татарчага тәрҗемә итүгә омтылыш күзәтелде. Әлбәттә, тулаем алганда, бу уңай күренеш. Сүз була торып, аның урынына алынма сүз куллану гаять урынсыз.

Хәзерге татар-рус икетеллелеге шартларында тел, сөйләм культурасы, милли телнең чисталыгы мәсьәләләре үзәктә тора. Кирәксезгә рус сүзләре кулланып сөйләшү әдәпсезлек, тәртипсезлек билгесе икәнен истән чыгармаска кирәк. Каюм бабайның эшчәнлеге-милләткә фидакарьләрчә хезмәт итүнең бөек бер үрнәге. Аның китаплары-хәзерге милли тормышыбызга да аваздаш булган бай мирас.

**Файдаланылган әдәбият**

I. Асадуллин А. Каюм Насыйри (Тууына 140 ел тулу уңае белән) / Совет мәктәбе.-1965.- №2

II. Миңнегулов Х., Гыймадиева Н. Татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2011

III. Хуҗиәхмәтов А.Н. Мәгърифәт йолдызлыгында. – Казан:Матбугат йорты, 1998.

# ГАЛИМНӘР ГАЛИМЕ
# (ЯКТАШЫБЫЗ ГАЛИМ, МӘГЪРИФӘТЧЕ ВӘЛИ ХАҖИЕВНЫҢ ГЫЙЛЬМИ ЭШЧӘНЛЕГЕ)

**Закирова Фәридә Марат кызы**
*Тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*
**Загитова Зинфера Ильяс кызы**
*Туган тел укытучысы*
*Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Мәлбагыш авылы урта гомуми белем бирү мәктәбе»*

Туган як!.. Нигә син шулкадәр йөрәккә якын, күкрәкләргә кысып сөярлек газиз икән?! Синдә искән җилләр дә назлырак, һавасы да сафрак, кешеләре дә мәхәббәтлерәк. Әйе, һәркем өчен үз төбәгеннән дә матуррак, гүзәлрәк җир юк шул. Минем өчен дә нәкъ шулай. Өзелеп яратам үз ягымны, үз табигатемне, хезмәт сөючән, тыйнак авылдашларымны. Аларның һәркайсы аерым мактауга, хөрмәткә лаеклы. Һәр авылда шәхес дип аталырлык башкалардан аерылыбрак торучы кешеләр була. Әлеге язмамда әнә шул авылдашларымның берсе турында язып үтәсем килә. Аның хакында күпләр белми дә, чөнки артык тыйнак, халкыма хас сабыр шул ул. Ә бит өйрәнәсе иде аның тормыш юлын, иҗатын тиешенчә бәялисе иде. Дөрес, күренекле якташларың тормышын, гыйльми эшчәнлеген өйрәнүгә кызыксыну беркайчан да кимеми. Ул һәрвакыт актуаль.

Шуннан чыгып фәнни-тикшеренү эшебезнең максаты:

1. Азнакай ягы күренекле шәхесләренең иҗади мирасын өйрәнүн дәвам итү.
2. Туган татар телне өйрәнүгә кызыксыну булдыру.
3. Авылдашым, галим, укытучы, мәгърифәтче Вәли Хаҗиәхмәт улы Хаҗиевның гыйльми эшчәнлеген өйрәнү, райондашлары, авылдашлары арасында тоткан урынын ачыклау.

Максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар билгеләнде:

1. Милли гореф-гадәтләребезгә, рухи байлыгыбызга мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияләү.
2. В. Хаҗиев турында материал туплау.
3. Мәгърифәтченең иҗаты белән танышу.
4. Гыйльми,публицистик эшчәнлеген өйрәнү.
5. Мәгърифәтче турында замандашлары фикерен белү.

Төп эшебездә өйрәнү объекты – В. Хаҗиевның тормыш юлы, гыйльми эшчәнлеге. Предметы – әдәбият фәне.

Фәнни эшебездә: өлешчә эзләнү, тикшеренү, чагыштыру, анализ кебек метод-алымнарын файдаландык.

Эшемнең фәнни-практик әһәмияте. Һәрнәрсәнең, һәркемнең үз тарихы, үз язмышы бар. Тарихын белгән, татар исемен горур йөрткән киләчәк кешесе, беркайчан да үткәннәрне хәтерләүдән курыкмас. Хезмәтебездә чагылыш тапкан, материал һәм мәгълүматлар кечкенә генә тарихи истәлек итеп саклавын күрсәтүче дәлил буларак та әһәмияткә ия. Шул ук вакытта В. Хаҗиевның тормыш юлын, шәхесен, гыйльми эшчәнлеген өйрәнүчеләр өчен дә күпмедер дәрәҗәдә файдалы булыр дип уйлыйбыз.

Мәгърифәтче В Хаҗиев үзе исән вакытта үз куллары белән язып калдырган автобиографиясе, китаплары, «Ватаным Татарстан», «Маяк», «Шәһри Казан» газеталарында чыккан мәкаләләр безнең өчен төп фәнни әдәбият булды. Фәнни эшебез кереш, төп өлеш һәм йомгаклаудан тора. Ахырдан кулланылган әдәбият исемлеге бирелде.

## ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ «МӘХӘББӘТ ТӘҮБӘСЕ» ПОЭМАСЫ ҺӘМ АНЫҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Зарипова Алсу Рәшит кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районы ГБМБУ «89 нчы мәктәп»*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Теманың актуальлелеге**:** телдән сөйләү тиз фикерләүне, кыска гына арада тиешле сүзне табуны сорый. Әгәр кешенең сүз байлыгы җитәрлек түгел, ярлы икән, аның уй-хисләрен аңлатырга сүзләре табылмый. Бик күп туры килми торган сүзләр, пауза-тукталышлар килеп чыга. Димәк, безгә матур әдәбиятны укып, сүз байлыгын арттырырга кирәк. Матур әдәбият теле – образлы тел**.** Анда сурәтләү чаралары аша һәр язучының сөйләм үзенчәлеге күренә. Автор кулланган чаралар, алымнар җыелмасы язучының дөньяга карашын, иҗат ысулының юнәлешен дә билгели. Язучы сүзләрне билгеле бер максат белән сайлап ала, урнаштыра. Шуңа да сүзнең мәгънәлелеген, тәэсирлеген, синонимнарын, антонимнарын табу сүз белән эшләүнең бер төре булып тора.

Татар теленнән тиешле белемне алуда матур әдәбият әсәрләренең тел үзенчәлекләрен өйрәнү әһәмиятле юнәлеш булып тора. Әдәби әсәрләрдә тормышның төрле өлкәләре, төрле чорга караган вакыйгалар сурәтләнә,

шунлыктан аларда телнең сүз байлыгы һәм сөйләм үзенчәлекләре шактый тулы чагылыш таба. Бу исә тел материалын тормыш белән бәйләп өйрәнүгә ныклы нигез бирә.

Әдәби әсәр телен анализлаганда, гадәттә андагы сурәтләү чараларына, мәкаль һәм әйтемнәргә, телнең образлылыгына, стиль үзенчәлекләренә игътибар ителә. Әлеге чараларны барлау һәм анализлау укучыларның сөйләм телен үстерүгә, тел фактларын аңлап үзләштерүләренә зур ярдәм итә.

Әдәбият – тормыш дөреслеге, кеше турындагы гыйлем. Ә тел – әдәбиятның беренче элементы. Әдәби әсәрнең сәнгатьчә эшләнешен, тел-стиль чараларын өйрәнү – укучыларның эстетик зәвыгын формалашу, матурлыкны тою, туган телнең эчке серләрен, потенциаль мөмкинлеген тирәнрәк үзләштерү, сөйләмен үстерү, дөньяга карашын киңәйтүгә, әсәрне аңлауга, язучының осталыгын билгеләүгә зур ярдәм итә.

Һади Такташ – поэма жанрында иҗат иткән шагыйрь. Без анализлау өчен «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасын алдык. Хезмәтнең максаты – «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасынында чагылган тел бизәкләрен анализлау.

Максатка ирешү барышында түбәндәге бурычлар куела:

1) «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасын уку.

2) Тел-сурәтләү чараларына төшенчә бирү.

3) Әсәрдә тел-сурәтләү чараларының бирелеше.

Өйрәнү объекты – Һади Такташ «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы, предметы – тел үзенчәлекләре.

Хезмәтнең фәнни (гамәли) әһәмияте – бу материалларны дәрестә яки дәрестән соң чараларда кулланырга мөмкин.

Хезмәтнең структурасы кереш, ике бүлек, йомгак, кулланылган әдәбият исемлегеннән гыйбарәт. Беренче бүлек «Нәрсә ул тел сурәтләү чаралары?» дип исемләнә. Анда тел сурәтләү чаралары турында сүз бара. Икенче «Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында тел үзенчәлекләре» дип исемләнгән бүлектә әсәрдә кулланылган тел сурәтләү чаралары хакында сүз алып барыла.

Проектның төре: эзләнү – тикшеренү характерындагы эшчәнлек.

Һади Такташ – поэма жанрында колач салып йөзүче шагыйрь. Аның поэмалары жанр төрлелеге ягыннан да, тел-сурәтләү чаралары җәһәтеннән дә гаять төрле. Аның поэмалары жанр төрлелеге ягыннан да, тел-сурәтләү чаралары җәһәтеннән дә гаять төрле.

«Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында яшьләрнең тормышы, хезмәтләре, аларның тормыш-көнкүрешләре, сөенеч-көенечләре сурәтләнә. Төп геройлар Зөбәйдә һәм Мәхмүт. Зөбәйдә –комсомолка кыз, чибәр. Карт

әнисе белән яши. Мәхмүт – «наборщик», ягъни хәреф җыючы булып эшли. Ләкин гадәти генә эшче түгел, ул җыелышларда доклад сөйли, театрга йөри. Димәк, сәясәттән, сәнгатьтән читтә тормый торган кеше. Шул ук вакытта ул яңа тормышта әхлакның нигезе «ирекле сөю» булырга тиеш дип уйлый. Бу аның ялгышы. Мәхмүт күз алдына китергән «ирекле мәхәббәт» – кешенең татлы кичерешләреннән, аның омтылышларынна көлү ул. Егет кызны чын күңелдән сөйми, бик җитди түгел ул. Мәхәббәтне күңелле вакыт уздыру өчен генә кирәк дип карый ул. Бала тугач, егет үкенә башлый, алар янына килә, гаилә тулылана.

Шул хисләрнең ни дәрәҗәдә икәнен күрсәтү өчен язучы төрле тел үзенчәлекләрен куллана. Әдәби әсәрләрдәге фразеологик әйтелмәләр, тел бизәге буларак, идея-эчтәлекне ачыклауга зур ярдәм итәләр. Алар ярдәмендә әдәби әсәрнең сыгылмалылыгы арта, сөйләм образлырак, тәэсирлерәк була, мәгънә тирәнлеге көчәя.

Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында фразеологизмнар, сурәтләү чарасы буларак, һәр вакыйганы, образларның характерларын тагын да ачыграк итеп күрсәтергә ярдәм итәләр.

Предметлы сурәтләү чаралары – синонимнар, антонимнар, эпитет, чагыштыруларны кулланып, шагыйрь сүзләрдән үзенчәлекле бизәкләр ясый, укучы сихри дөньяга алып кереп китә. Парлы сүзләрне текстта куллану поэманы җанландырып, матурландырып җибәрә.

Поэтик чагыштырулар еш кына персонажның эчке хисләрен төгәлрәк билгеләргә ярдәм итеп торалар. Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында да моңа мисалларны шактый табып була.

Шагыйрь үзе дә хикмәтле сүз остасы. Тел бизәкләрен үзенчәлекле кулланып, әдип шигъри сөйләмне аһәңле, образлылык ягыннан тагын да тирән мәгънәле итә. Һади Такташ бу поэмада тел бизәкләрен үзенә генә нечкә тоем белән, эчке сиземләү белән куллана. Аларны кат-кат укып, шигъри бизәкнең мәгънәсенә төшенеп, күнел түренә салып куйгач, алардан аерыласы да килми.

Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы һәм аның тел үзенчәлекләре темасын өйрәнгәннән соң шундый нәтиҗәгә килдек. Тел үзенчәлекләре ягыннан, Һади Такташ шигърият әсәрләрендә без түбәндәгесен билгеләп киттек. Табигатьне, техниканы, персонажларны һәм аларның тойгыларын, башка күренешләрне һәм вакыйгаларны тасвирлаганда шагыйрь еш киң метафоралар, эпитетлар һ.б. чаралар куллана. Күбесенчә, бу алымнар табигать күренешләренә карата кулланылган.

1) Шагыйрьнең яшьлеккә, гашыйк булуга мөнәсәбәтен күрсәтә («Яшьлек, Гомерең кыска синең...» ).

2) Табигать күренешләре аша Зөбәйдәнең мәхәббәт хисләрен һәм ялгыш адымын чагылдыра

(Сандугач таңнарда...).

3) Автор ялгыз ай образы аша Зөбәйдәнең Мәхмүтне көтүен сурәтли.

(«Ай да ялгыз, Безнең Зөбәйдә дә...»).

4) Автор җилнең ачуы аша Зөбәйдәнең эчке хис- кичерешләрен күрсәтә

(«Урам буйлап җил бер ис(е)рек белән... ».

5) Шагыйрь Ана образына дан җырлый («-Тукта, елау таушы килә...»).

6) Шагыйрь песи малае образы аша ятимлек проблемасын күтәрә

(«Елап утыра песи малае... »).

7) Шагыйрь төрле проблемаларга карамастан тормышның җайлануын, дәвам итүен искәртә

(«Ә ай күктә һаман сүгенеп йөри... »).

## БӨЕК МӘГЪРИФӘТЧЕ – ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘСЕН ӨЙРӘНҮ

**Захарова Мария Павловна**

*Казан шәһәре Авиатөзелеш районының*

*«145 нче лицей» гомуми белем муниципаль учреждениясе*

*Югары квалификацион категорияле*

*туган тел укытучысы*

Үткәне барның, киләчәге бар – ди халык. Шул максаттан чыгып, мин нәсел шәҗәрәләрен өйрәнүгә үз хезмәтемдә зур урын бирәм.

Нәсел шәҗәрәсе төзү традициясе татар халкында бик тә борынгыдан килгән. Җиде буын ата-бабасын белү һәр татар кешесенең изге намус бурычы булган. Мин үз эшемдә бу традицияләрне торгызу өстендә эшлим. Балалар үзләренең туганнарын барлыйлар, алар турында мәгълүматлар җыялар. Бүгенге көндә без балаларның туганнары, якыннары турында гына түгел, ә бөек шәхесләребез турында да күпләп мәгълүмат җыю белән шөгыльләнәбез. Ә инде укучыларның үз шәҗәрәләрен тикшерү барышында нәселләрендә күренекле шәхесләрне ачулары икеләтә шатландыра менә шундый эшләремнең берсе турында тирәнрәк тукталырга телим.

Сезнең игътибарыгызга Ш. Мәрҗанинең нәсел шәҗәрәсен тәкъдим итәм.

Мәрҗаниләр нәсел шәҗәрәсе Мәрҗан авылыннан килә. Бу авылга нигез салучы Габделкотдус булган. Ә оныклары – Субхан һәм Баһаутдин

тарих белән кызыксынганнар, үзләренең улларына күп истәлекле вакыйгалар турында сөйләргә яратканнар. Алар шул чорда ук инде мәктәп-мәдрәсә тотканнар. Аларның белемгә омтылулары, илебез тарихы белән кызыксынулары, әлбәттә, эзсез югалмаган, буыннан буынга күчә килгән.

Бу нәселдән чыккан берничә шәхескә тукталыйк.

Ш. Мәрҗани – безнең илебез тарихына нигез салучы. Үзе дә күренекле мәгърифәтче булган шагыйрь Гали Чокрый аны татар халкының сүнмәс шәменә тиңләгән, Тукай аны остазы итеп санаган, ә Җамал Валиди: «Ул тарихның атасы» – дигән. Ш. Мәрҗани Урта Азиядә белем алып кайткач, Казанның беренче мәчетенә имам итеп билгеләнә, 40 ел дәвамында Мәрҗани җитәкләгән мәчет хәзер аның исемен йөртә. «Мостафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабы Мәрҗани язган иң күренекле тарихи хезмәт булып санала. Өстәп әйтергә кирәк, Учительская школа ачылгач, В.В Радлов үтенече белән Мәрҗани анда дин белемнәре өйрәтүче булып эшли.

Шиһабетдин белән бертуган Галәветдиннең улы – публицист, драматург, шагыйрь, тәрҗемәче, күп сатирик әсәрләр авторы Мәхмүт Галләү турында да күпләрнең ишеткәне бардыр. Ул хөкүмәт тарафыннан 1938 нче елда атып үтерелгән. Шиһабетдин белән бертуган Галәветдиннең улы – публицист, драматург, шагыйрь, тәрҗемәче, күп сатирик әсәрләр авторы Мәхмүт Галәү.

XX йөз татар реалистик прозасының күренекле вәкиле, татар әдәбиятында тарихи роман жанрына нигез салучыларның берсе Мәхмүт Галәү (Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани) 1886 елның 8 ноябрендә хәзерге Татарстан Республикасының Арча районы Ташкичү авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Большевиклар инкыйлабына кадәр Мәхмүт Галәү үзе дә, әдип һәм журналист буларак, язган әсәрләрен «Мәрҗани» имзасы белән бастыра.

Туган авылында әтисе Галәветдин хәлфәдән укып, башлангыч мәктәпне, аннары Казанда «Мәрҗания» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, унҗиде яшьлек егет 1903 елда үз көнен үзе күрергә дип Әстерхан шәһәренә юл тота һәм шундагы татар мәктәпләренең берсендә мөгаллим булып эшли башлый. Әстерханда М.Галәү 1907 елның ахырларына кадәр яши. Өч-дүрт ел дәвамында шәһәрнең хөр фикерле зыялы шәхесләре белән даими аралашып яшәү, төбәктәге демократик рухлы мөселман яшьләре оештырган төрле милли-мәдәни чараларда, әдәбият-сәнгать кичәләредә һәм театр тамашаларында катнашу яшь егетнең дөньяга карашы, иҗтимагый-сәяси омтылышларының билгеле бер юнәлештә формалашуына ярдәм итә. Бу елларда М.Галәү журналистика юнәлешендә

дә зур тәҗрибә туплый. «Туп» журналын чыгаруга катнашканы өчен М.Галәү Әстерхан охранкасы тарафыннан эзәрлекләнә башлый һәм даими күзәтү астына алына; тора-бара охранка аны мәктәптә балалар укыту хокукыннан да мәхрүм итүгә ирешә. Әдип 1907 елның ахырларында Әстерханны ташлап Оренбург шәһәренә күчеп китәргә мәҗбүр була.

Оренбург чоры (1907–1918) – М.Галәү гомеренең тышкы яктан иң тыныч-хәвефсез, эш һәм иҗаты өчен шактый киң мәйдан, мөмкинлекләр ачылган еллар. 1914 елдан «Кармак» исемле юмор-сатира журналын чыгара; популяр характердагы фәнни рисаләләр, уку-укыту кулланмалары, дәреслекләр бастыруны җәелдереп җибәрә.

Җыеп әйткәндә, Мәхмүт Галәүнең 1917 елга кадәрге иҗтимагый-мәдәни һәм әдәби эшчәнлеге күп тармаклар буенча бара. Бу чорда ул татар әдәби-мәдәни фикер дөньясының алгы сызыгыннан атлаган талантлы журналист һәм публицист, тәҗрибәле нашир вә матбагат белгече, оста оештыручы һәм халыкка аң-белем таратучы мәгърифәтче булып танылa.

1919 елда ул – Башкортстан Халык Мәгарифендә мәктәпләр секторы мөдире, 1920 елда – Оренбург губернасының мәгариф бүлегендә нәшрият эшләрен җитәкли, 1921 елда – Мәскәүгә чакырылып, анда «Шәрык» бүлегенә әдәбият бастыру эшләре буенча җитәкче итеп билгеләнә. Мәскәүдә яшәгән елларында Мәхмүт Галәү – Мәскәү комитеты әгъзасы, ревизия комиссиясе әгъзасы, Үзәк әдәби кабинетта консультант, әдәби тел түгәрәгенең җитәкчесе була. Гомеренең соңгы елларында ул СССР Язучылар берлеге каршындагы тәнкыйть-библиография бүлегендә эшли. Барыннан да бигрәк шушы елларда әдип үзенең күңеле түрендә күптәннән йөрткән иҗади хыялын – татар халкының зур бер чор эчендәге тарихи тормышын иңләп алган эпопея язу турындагы ниятен эшкә ашырырга керешә. Гомуми исеме «Канлы тамгалар» дип алынган бу эпопея дүрт китаптан торырга тиеш була. Әдип алдан һәр китапның киңәйтелгән планын төзи, исемнәрен билгели. Беренче китапта XIX гасыр татар авылының, авыл һәм шәһәр халкының 1877 елгы ачлык фаҗигасен кичерү вакыйгаларын, икенче китапта 1897 елгы халык исәбен алу, шуңа бәйле рәвештә авыл халкының бунт күтәрүе һәм соңыннан Төркиягә күчеп китүе, өченче китапта рус-япон сугышы һәм 1905 елгы беренче инкыйлаб чоры һәм, ниһаять, «Өермәләр» дип исемләнгән соңгы дүртенче томда большевиклар инкыйлабы елларындагы давыллы вакыйгаларны гәүдәләндерү күздә тотылган була. Ләкин, язучының фаҗигале язмышына бәйле рәвештә, роман-эпопеяның беренче ике китабы гына язып тәмамлана, өченче, дүртенче кисәкләре, каралама хәлендә әзер булсалар да, әдипнең кульязма архивы һәм беренче ике кисәгенең асыл нөсхәләре

белән бергә юкка чыгалар. Беренче ике кисәген тәшкил иткән «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары 1930–1934 елларда Мәскәүдә «Муть», «Мухаджиры» исемнәре белән русча басылып чыга. Ә Мәхмүт Галәүнең үз кулы белән язылган тәүге вариантның әле дә булса табылганы юк.

1937 елның 7 октябрендә Мәхмүт Галәүне Төркиягә качып киткән татар мөһаҗирләренең язмышын ачыклау, алар урнашкан авылларны күреп кайту һәм уйланылган романнарына мәгълүмат туплау өчен Төркиягә барып кайтканы өчен булмаган җинаятьләр кылуда гаепләп кулга алалар һәм үлемгә хөкем итәләр.

Р. Мостафин «Репрессияләнгән татар әдипләре» китабында М. Галәү турында болай яза: «М. Галәү 1886 нчы елның сентябрь аенда туа. М. Галәүнең кайчан һәм ничек кулга алынуы төгәл билгеле түгел. Истәлекләргә караганда, аны Мәскәүдән Казанга сорау алырга китерәләр. Махсус киңәшмә утырышы 1937 нче елның 4 ноябрендә була (карары билгесез). НКВД белешмәсенә караганда, язучының гомере 1938 нче елның 12 нче ноябрендә өзелә».

1937 нче елның архив документларына күз салыйк: 1937 елның 7 октябрендә Мәхмүт Галәү кулга алына. 22 октябрьдә аннан беренче мәртәбә сорау алу турындагы белешмә, шул дата белән М.Галәүнең шәхси анкетасын күрәбез. 26 октябрь һәм 3 ноябрьдә сорау алу тагын кабатлана. Ә 4 ноябрь көнне, Октябрь бәйрәме алдыннан, «гаделләрдәнгадел» совет суды хөкем чыгара. Хөкем сүзләре яңгырауга, шул кичтә үк татар әдибен атып үтерәләр. Качаклар турында язып Россия тәртипләренә протест белдерергә батырчылык кылган 51 яшьлек әдипнең язмышы бер ай эчендә хәл ителә.

Шиһабетдин белән бертуган Садретдин, Ташкичүдә калып, атабабасының укытучылык эшен дәвам итүче булган. Аннан соң бу эшне аның улы – Габделмомин һәм оныгы – Габдрахман дәвам иткән.

Садретдинның икенче улы – Зәкәрия «Кояш» газетасында редактор булган, Фатих Әмирхан белән бергә эшләгән.

Садретдинның оныгы – Зөбәйдәнең тормышы җиңел булмаган. Ире Советлар власте тарафыннан кулга алынгач, аны ике баласы белән Себергә озатканда поездан сикереп төшеп кача һәм Үзбәкстанга юнәлә. Анда исемен, чыгышын яшереп гомер итә. Аның улы – Рөстәм – Ленинградтагы Авиаприбортөзелеш институтын тәмамлый һәм медицина өлкәсендә югары уңышларга ирешә. Рөстәмнең улы – Илдар Мәскәү фәнни-тикшеренү институтын җитәкли.

Күргәнегезчә, бу нәселдән илебез тарихында тирән эз калдырган укытучылар, табиблар, журналистлар, галимнәр, мәгърифәтчеләр күп чыккан. Гомумән, бу нәсел шәҗәрәсе белән илебез тарихын өйрәнеп булыр иде.

Укучылар белән бу юнәлештә эшләү – аларны эзләнергә этәрә. Алар тарих һәм әдәбият дәресләрендә шул чорда яшәгән үз әби-бабаларының, туганнарының тормыш – көнкүрешен күз алдына китерәләр. Ә бу инде әдзбиятны аңлау өчен беренче зур адым, чөнки әсәрне бәяләүдә безгә тарихилык принцибы ярдәм итә. Халкыбызның рухи байлыгын күрсәтә белү балаларда үз милләтенең әдәбияты белән горурлану, аңа соклану аркылы алып барылырга тиеш. Әдәбият дәресләрендә бу бурычның алга чыгуы – туган телгә, милли тарихка, милләткә мәхәббәт тәрбияләү дигән сүз ул. Үзенең үткәненә, тарихына хөрмәт белән караган халыкның гына киләчәге бар.

Чыгышымны Р. Фәйзуллин сүзләре белән тәмамлыйсы килә:

Киләчәккә аек карар
Үз тарихын анык белгән!
Хәтерләүдән курыкма син!
Ил үткәнен онытма син!

## МӘКТӘПЛӘРДӘ МИЛЛИ КОМПОНЕНТНЫ КӨЧӘЙТҮ ЮЛЛАРЫ

**Исрафилова Фәйрүзә Сәлихҗан кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган*
*71нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе»*
*гомуми белем бюджет муниципаль учреждениесе*
*Биология укытучысы*

Мәктәпләрдә милли компонентны көчәйтү өчен мин өч адым ясау кирәк дип саныйм:

1. Милли компонент мәктәп белән чикләнмичә, яшәү тирәлеген дә биләргә тиеш.
2. Укытучылар укучыларны кызыксындырган юнәлешләрдән хәбәрдар булып, заман шаукымын тоеп торырга тиеш.
3. Төп предметларның фәнни-методик базасы татар телендә сыйфатлы дәрәҗәдә булып, интернет платформалары ярдәмендә киң кулланылышка кертелергә тиеш.

Бүгенге вәзгыять мәктәпләр алдында бик күп төрле сораулар куя. Милли компонент булган мәктәпләрдә ул сораулар һәм проблемалар икеләтә күп, дияр идем мин. Балаларга фәннәрне төпле һәм сыйфатлы дәрәҗәдә укыту белән бергә, туган телләрен һәм милли традицияләрне саклап калу проблемасы да килеп кушыла. Һәм бу бүген генә килеп чыккан мәсьәләләр түгел. Тарихка әйләнеп карасак, татар җәмгыяте өчен белем бирү процессы һәрвакыт бәхәс мәйданы булып тора. XX гасыр башында булган кадимчелек белән җәдидчелек тартышуын гына искә алыйк.

Егерменче гасыр башында иҗат иткән күренекле сәясәтче һәм публицист Гаяз Исхакый үзенең иҗатында татар мәгърифәтенә юкка гына зур игътибар бирми. Үзенең мәкаләләрендә мәктәпләрне ул татар халкының җаны, дип атый. Татар мәктәпләренә урыс телен кертуне, милләт тамырына балта белән сугуга тиңли. Татар мәгрифәтчеләрен урыс галимнәренә һәм аларның казанышларына игътибарны көчәйтергә өндәсә дә, татар теленә карата һәм татар теленең мәктәптәге урынына карата аның фикере катгый. Мәктәпләрдә ана теле мәкаләсендә ул: «... *мәктәпләремездә тәгълим үз телемездә булсын, мәктәпләремез үз ихтиярымызда булсын. Һәм бу көнге көндә мәктәпләремез үз телемездздер, үз ихтиярымыздадыр, киләчәктә дә шулай булачактыр. Чөнки таза, яшь бер милләт һичбер вакытта үз рухының ят бер эш белән сугарылуына разый булачак түгелдер...* »

Егерменче гасыр башында ук язылган бу мәкаләдән соң, татар мәгърифәте күптөрле үзгәрешләр кичерде. Кызганычка каршы, шушы мәкаләсендә төп сорау булып күтәрелгән, татар мәктәбендә башлангычны урысча укыту тәкъдименә каршы чыгуы булса, бүген инде татар мәктәбенә татарлыкны кайтару соравы карала.

Әйтергә кирәк, Гаяз Исхакый үзе дә Казанда Укытучылар мәктәбендә укытканда, шәкертләре тарафыннан зур хөрмәткә ия була. Шәкертләре аның заман белән бер аяктан атлавы, алдыгы карашлары һәм төпле тирән белемнәре өчен хөрмәт итә. Бу сыйфатлар егерменче гасыр укытучысы өчен генә түгел, бүгенге заман укытучылары өчен дә актуаль булуын дәвам итә. Димәк, балаларда татар теленә һәм традицияләргә кызыксыну уяту өчен, аларның мәктәп эчендә генә түгел, гомумән, яшәү тирәлегендә дә милли мөһит тудырырга кирәк. Милли компонент мәктәп диварлары белән генә чикләнсә, балалар аны ясалма бер дөнья итеп кабул итә, тормышта аның кирәген сизми. Димәк, яшьләрдә кызыксыну уяткан даирәдә татар теле булырга тиеш, тәрҗемә хәлендә булса да.

Татар теле һәм әдәбияты фәннәренә килгәндә, интернетта инде байтак кына материал табып була. Балалар шул фәннәрдән өй эшләрен

әзерләгәндә, азмы-күпме өстәмә информация, аңлатмалар таба алалар. Башка төп фәннәргә килгәндә, татар телендә өстәмә аңлатмаларны бары тик рус телендә генә табып була. Әгәр дә без балаларга татар мәктәпләрендә төп фәннәрне татар телендә бирергә уйлыйбыз икән, укучылар өчен дә, укытучылар өчен дә фәнни-методик базаны татар теленә дөрес итеп тәрҗемә ясап, интернетка төрле платформаларга урнаштырырга кирәк. Чөнки, бала дәрес әзерләгәндә, үзенә кирәкле информацияне таба алмыйча, предметтан начар билгеләр ала торган булса, аның фәнгә карата гына түгел, ана теленә карата да, күңеле сүреләчәк. Мин, мисал өчен, биология укытучысы буларак, бу предметтан татар телендә фәнни-методик базаның шактый йомшак булуын ассызыклыйм. Мисал өчен, биологиядән татар телендә олимпиада булып узды, олимпиада сораулары арасында «килешү яки килешмәү» биремендә:

«Сабак хайваннарында җыерчыклы тешләрнең барлыкка килүе тупас үсемлек азыгын тукландыруга җайлашу булып тора». Бу бернинди дә мантыйкка сыймый торган сүзләр җыелмасы. Теркәлгән терминологиядә кулланылмаган, җөмләнең башы да, ахыры да юк. Сабак хайваннары, русчадан «травоядные животные» дигәннең уңышсыз тәрҗемәсе була, дип фаразлыйк. Дөресе – үлән белән тукланучы хайваннар, булыр иде. Шунда ук: «Аккомодация – даими рәвештә аның ачуын чыгарган рецепторның сизгерлеге бусагасын үзгәртү», – дигән җөмләне укыйбыз. Биология предметын укыткан укытучылар рецепторның ачуы чыкмаганны, әлбәттә, беләләр, рецепторлар ярсый. Мондый уңышсыз тәрҗемәле сораулар фәнгә карата ниндидер кимсетү хисләре уята. Бу сорауларны әзерләүчеләр, димәк татар телен, яисә биология предметын татар телендә кирәкле дәрәҗәдә белмиләр. Кызганыч, биология фәне барлык татар телендә белем бирүче мәктәпләрдә дә татар телендә укытылмый. Сәбәбе татар телендә укыта алырлык, биология фәнен татар телендә камил белүче кадрлар юк дәрәҗәсендә дип уйлыйм. Чөнки югары уку йортларында биология фәне татарча укытылмый. Мөгаен, фәнни-методик әсбаплар базасы тиешле дәрәҗәдә түгелдер.

Димәк, мәктәптә милли компонентны көчәйтүнең өч юлын күрсәтеп була. Беренчедән, укучыларның мәктәптән тыш кызыксынган тирәлектә милли тормышны, татар телен булдыру, аларга заманча яңгыраш бирү. Икенчедән, укытучыларның заман белән бер аяктан атлап, яшьләрнең кызыксыну тирәлеге белән хәбәрдар булуы. Өченчедән, фәнни-методик базаның татар телендә тиешле сыйфатта булуы. Болар барысы да безнең кулдан килә торган эш һәм бездән башка, аны беркем дә эшләмиячәген аңлау кирәк.

# ФОАТ САДРИЕВ ӘСӘРЛӘРЕ РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН НӘСЫЙХӘТЛӘРЕ ЯССЫЛЫГЫНДА

**Нәҗмиева Гөлнар Ленар кызы**
*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе» Туган тел укытучысы*

Вакыт узган саен, дөнья үзгәрә. Кешеләр, аларның карашлары, әхлакый кыйммәтләр дә, вакытка ияреп, үзгәреш кичерәләр. Шул исәптән тәрбия өлкәсе дә үзгәрешләргә дучар була. Үз кыйблаңны ничек дөрес табарга? Ничек итеп шушы яңалыклар белән тулы дөньяда югалып калмаска?

«...Тәрбия булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә, гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия иң кирәкле бер эш булачактыр», – дигән мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин үзенең бер хезмәтендә.

Ә нәрсә соң ул тәрбия? Балага ничек дөрес тәрбия бирергә? Бала күңеленә ничек итеп матурлык, шәфкатьлелек орлыкларын чәчәргә соң? Әлбәттә, әдәбият-сәнгать аша дип җавап бирер идем мин. Әдәбият, сәнгать белән кызыксынган, китапларны чын күңеленнән яратып укыган баланың белеме дә тирәнрәк, күңеле дә бай була. Аның күркәм эшләр башкарырга омтылышы да көчәя.

Үзенең «Тәрбияле бала» исемле китабының иң башында мәшһүр галимебез Р. Фәхреддин тәрбияле баланың нинди булырга тиешлеген, андый баланың җәмгыять өчен нинди зур байлык икәнлеген күрсәтеп, болай дип яза: «Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр...»

Мин үземнең педагогик хезмәтемдә матур әдәбиятка һәм Р.Фәхреддин нәсыйхәтләренә бик еш мөрәҗәгать итәм. Тәрбия сәгатеме ул, дәрестән тыш уку дәресеме, класстан тыш чарамы – һәркайсында аларга өстенлек бирәм. Ә бүгенге сүзем якташыбыз, Мөслим районының Г.Тукай исемендәге премия лауреаты, халык язучысы, прозаик, драматург Ф.Садриев әсәрләренең тәрбияви әһәмияте һәм мәшһүр галимебез, бик күп хезмәтләр авторы, педагог Р.Фәхреддин нәсыйхәтләре турында булыр.

Фоат Садриевның хикәя, повестьлары – бик эчтәлекле һәм гыйбрәтле әсәрләр. Әйдәгез, әдипнең берничә әсәренә һәм аларга мөнәсәбәтле рәвештә Р.Фәхреддин хезмәтләренә мөрәҗәгать итик.

«**Рәхмәт, этием!**» повесте беркемне дә битараф калдырмагандыр, мөгаен. Әлеге әсәрне укып бетерү белән уйга чумасың. Гөнаһ җәзасыз калмый... Нәкъ менә шушы фикер туа минем күңелемдә. Кеше тормышында бер мизгел язмышны үзгәртә ала. Һәркем вакытында, акылын җыеп: «Тукта, мин нишлим?» – дигән сорау куя белергә тиеш. Безнең һәр адымыбыз җаваплы. Гөнаһларыбыз күпме вакытлар аша үтсә дә, тормышыбызда чагылыш таба һәм алар җәзасыз калмый. Хикәядә без шуны күрәбез дә. Әсәрне укыганда, соңгы мизгелгә кадәр улының үлеменә ышанмыйсың, әйтерсең бу изге җан берничек тә фани дөньядан китә алмый, моның булуы мөмкин хәл түгел... Ул олы җанлы бала. Кичерә белә. Әтисенә бер авыр сүз дә әйтми. Үлеме якынлашканда гына: «Минем энемә сукмагыз», – дигән сүзне әйтә.

«Рәхмәт, этием!» повестен укып бетерү белән, үземә бу әсәрнең укучыларыма нинди тәрбияви әһәмияте бар дигән сорауны куйдым. Һәм шунда ук җавапны да таптым. Әсәрдән бала алырдай тормыш дәресләре: гөнаһ җәзасыз калмый; кичерә белү – алыштыргысыз бүләк; гаилә ныклыгы өчен татулык кирәк; һәрнәрсәнең кадерен бел; тугрылык – гүзәл сыйфат; үз хаталарын таный белгән кешенең киләчәге бар; кеше фикеренә колак сала белү – осталык; бер мизгел язмышны үзгәртә ала; сабыр төбе – сары алтын.

**Ризаэддин Фәхреддин нәсыйхәтләре**

«Өй эчендә булганнар белән гүзәл мөгамәләдә булу – шәригать каршында иң сөекле эштер. Вә шуның өчен өй эчендә булганнар хакында әдәпле вә миһербанлы булыгыз».

«Кешенең итагатьле булуы – күңеле яхшы булу галәмәтедер. Инде сезгә иң якын кешеләр дә әлбәттә ата вә аналарыгыздыр. Шуның өчен аларга һәрвакытта итагатьле булыгыз, гамәл вә сүздә аларга каршы килмәгез, бу сәбәптән аларның күңелләре дә рәхәтләнер, үз күңелләрегез дә вә дөньяда торуыгыз дә гүзәл булыр».

«**Кыргый алма эчесе**» повестеның да тәрбияви әһәмияте бик зур дип исәплим. Әнвәрә белән Вилданның матур гына башланган мәхәббәт тарихы сынаулар алдында кала. Вилдан мәхәббәт хакына корбан таләп итә, ә ул мәхәббәтнең юкка чыгуына, ике кешенең бәхетсезлегенә китерә.

Әйе, Вилданның үз-үзен яратуы күпләрне кыен хәлдә калдыра. Әсәрнең төп сюжет сызыгы Вилданның үз эчендәге каршылык барлыкка китерә. Ул – эгоизм. Вилданның Әнвәрәне һәм үз-үзен яратуы арасында бәргәләнүе, шул сәбәпле сөйгәнен югалту тарихы артистлар мохитендә тасвирлана.

Әсәрдәге Мансур һәм Нәсимә образлары да аерым игътибарга лаек. Мансур кешеләр өчен җанын ярып бирергә әзер торуы белән һәркемне

үзенә җәлеп итә. Ул яраткан кешесе мәнфәгатьләрен беренче планга куя. Повестьта төп урынны дүрт геройның эчке дөньясын, кичерешләрен, характерын сурәтләү алып тора. Әсәрнең буеннан-буена геройлар үз-үзләрен һәм башкаларны бәялиләр.

Геройларның һәрберсенә хас булган үзенчәлекле сыйфатлары бар һәм алар аша без үзебезгә күңелебездән бәя бирәбез. Ә мин нинди соң? – дип сорау куябыз. Әгәр дә кимчелекле якларбызны табабыз икән, тизрәк үзгәрергә ашкынабыз, чөнки бу яхшылыкка китермәскә мөмкин. «Кыргый алма әчесе» әсәре белән танышканнан соң, аннан түбәндәге сабакларны алырга була: эгоизм – начар сыйфат; һәркем үз юлын үзе сайларга хокуклы; үз бәхетең өчен көрәшә белерә кирәк; ярату ул – бер-береңне аңлау һәм кабул итү; үзен генә кайгырткан кеше бәхетле була алмас.

**Ризаэддин Фәхреддин нәсыйхәтләре**

«Кешенең матурлыгы – аның тәрбияле, эшчән, намуслы булуында, олыларны олы итеп, кечеләрне кече итеп яши белүендә».

«Күркәм тереклек – мәхәббәткә, мәхәбәттә-табигать берлегенә бәйле булуы өчен: тереклек иптәшләрегез белән табигатьләрегез дә яраклы булуына диккатъ итегез. Ягъни һәрникадәр мөшкел булса да – табигатьләрегездә берлек булган кешеләрне табарга тырышыгыз».

«Гаилә өчен куела торган кагыйдәләрне элегрәк белеп, вакыты җиткәндә аларны кулланган кешеләр үз гаиләләренең әдәп вә сәясәт хәлләрен күркәм рәвештә төзерләр... »

«Әдәп вә хая барлык кешеләрдә дә бертөрле булмый... » «Кешеләр көнләшмәсәләр, тынычлык вә яхшылык эчендә яшәрләр иде».

Бер карасаң, Фоат Садриев әсәрләрендә артык бер нәрсә дә юк кебек. Кичәге, бүгенге, үзебезнең тормыш... Геройлары, персонажлары, вакыйга барган урыннары да көн саен аралашкан, очрашкан, ачуланышкан, дуслашкан үз кешеләребез, урамнарын таптаган авылларыбыз, күнегеп беткән, исебез дә китми торган үз мохитебез. Ә шул җитди һәм юмор катыш сурәтләнгән гадәти мохит һәм вакыйгалар яшь буынга үз хокукларын һәм бурычларын белергә, нинди генә яшьтә булуыңа карамастан, һәрвакыт, һәркайда әхлакый тәрбияле булырга, дөнья киңлекләрен өйрәнергә, тормыш матурлыгын күрә белергә, дөрес яшәргә кирәклеген аңлаталар. Бүгенге көн әдәбиятының күренекле вәкиле Фоат Садриев әсәрләренең тәрбияви әһәмияте дә шунда.

Әдипләребез һәм мәгърифәтче-галим Риза Фәхрединнең әхлак тәрбиясе бирүдә халык традицияләрен, гореф-гадәтләрен, әхлакый кыйммәтләрен эченә алган мирасы, диңгез төпкелендәге мәрҗәннәрдәй, безнең буын укучылары өчен бик мөһим.

# РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН ҺӘМ КАЮМ НАСЫЙРИ ХЕЗМӘТЛӘРЕН ДӘРЕСЛӘРДӘ ҺӘМ СЫЙНЫФТАН ТЫШ ЧАРАЛАРДА КУЛЛАНУ

**Садыйкова Рәмзия Габидулла кызы**
*Казан шәһәре Киров районының*
*«4нче Гимназия-интернаты» муниципаль*
*автономияле гомуми белем учреждениясе*
*Туган тел укытучысы*

Тәрбия процессы – кешенең тулысынча шәхес буларак формалашуы ул. Ләкин шушы тулы бер процесста төп һәм иң әһәмиятле урынны әхлак тәрбиясе били. Әхлак тәрбиясе – тәрбия эше системасының үзәге, иң мөһим юнәлеше. Кеше үз эшчәнлеге дәвамында, аралашу вакытында дөньяга, кешеләргә мөнәсәбәттә әхлак нигезләрен туплый.

Бүгенге көндә кешегә рухи-әхлакый сәламәтлеген, милли-мәдәни үсешен, эчке тотрыклылыгын тәэмин итү, үзенең тәрбияви вазифаларын башкару мәсьәләләрен хәл итү бурычы тора. Бүгенге җәмгыятьтә кеше үзенең тормышын интернет челтәрләрсез күз алдына да китерә алмый. Бүгенге болгавыр әхлаксызлык күренешләре хөкем сөргән заманда фәнни-техник прогресс буенча үстерү ягына гына игътибар итәргә ярамый. Җәмгыятьтә тәрбиясезлек күренешләре артканнан-арта бара. Яшьләрнең компьютер һәм телефоннарга бәйлелек чире аларның хисэмоцияләренә, матурлыкны күрә белеп соклану һәм шул матурлыктан ләззәт табуларына янәшә тирәдәгеләр белән аралашу – аңлашуына киртә булып тора. Шушы замана «чирләрен» дәвалау – без укытучыларның төп бурычы булып алдыбызга килеп басты. Чынбарлык шуны таләп итә: гаиләне дөньяны әхлакый кагыйдәләргә кормый торып, без җәмгыять үсешенә ирешә алмаякчыкбыз.

Һәр халыкның тарихи мирасында күренекле шәхес, галим һәм фикер ияләренең иҗатлары, язган хезмәтләре зур урын алып тора. Безнең татар халкыбызның бай традицияле мәдәни һәм рухи мирасыбызда Ризаэддин Фәхреддин һәм Каюм Насыйрилар – кешене кеше һәм шәхес итеп тәрбияләүнең дөрес юлын күрсәтеп калдырган галимнәр.

Ризаэддин Фәхреддин үзенең «Гаилә», «Тәрбияле ана», «Тәрбияле бала», Каюм Насыйриның «Тәрбия» һәм «Әхлак рисаләсе» һәм башка бик күп китапларында бала тәрбияләү, гаилә ныклыгы һәм аның бәхетенә ирешү, үзеңне җәмгыятьтә тоту кагыйдәләрен, нәсыйхәтләрен үтемле, тормышчан итеп күрсәткән.

Шушы фәнни эшемдә мәктәпләрдә укучыларга әхлакый тәрбия бирү максатыннан, дәресләрдә һәм тәрбия сәгатьләрендә, ата-аналар конференцияләрендә куллану, гомумән, укыту-тәрбия эшенә эзлекле итеп кертү өчен тәкъдим итәм.

Бу фәнни эшемнең төп **максатлары**: укучыларга рухи-әхлакый тәрбия бирү, аларны гаилә тормышына әзерләү, бүгенге җәмгыятькә яраклы югары әхлаклы шәхес тәрбияләү.

Бу максатларны тормышка ашыруда түбәндәге **бурычлар** тора: Ризаэддин Фәхреддиннең китапларын өйрәнеп, хезмәтләрен темалап бүлү, дәрес һәм тәрбия сәгатьләре, ата-аналар конференцияләре һәм сыйныфтан тыш чаралар өчен план үрнәкләре, күнегүләр җыентыгы, викторина сораулары язу.

Бу фәнни эшем – баланы әхлакый тәрбияләүдә дөрес юнәлеш бирүче хезмәт. Җәмгыятьтә тамыр җәйгән тәртипсезлек һәм афәтләрдән арынырга, тормыш итүнең дөрес кыйбласын формалаштырырга ярдәм итә. Бу бик **актуаль** бүгенге көндә. Фәнни эшемнең **яңалыгы** шунда: мәгърифәтчеләрнең хезмәтләреннән генә алынган җөмләләр белән төзелгән күнегүләр җыентыгы да, әхлак тәрбиясе буенча эш программалары да әле юк диярлек. Моны башкаларга да таныту кирәк.

Монда 1 нче сыйныфтан алып 11нче сыйныф укучылары өчен бөек галимнәр Ризаэддин Фәхреддин, Каюм Насыйриларның хезмәтләренә нигезләнеп язылган эш үрнәкләре күрсәтелә. Аларга түбәндәгеләр керә: татар теле дәресләрендә «Гади җөмлә синтаксисы» һәм «Кушма җөмлә синтаксисы» бүлекләрен өйрәтү өчен күнегүләр җыентыгы, тәрбия сәгатьләре үткәрү өчен план үрнәкләре, викториналар өчен сораулар төзелде. Шулай ук 7-11 нче сыйныфлар өчен «Әхлак» программасы тәкъдим ителде. Бу план үрнәкләрен мәктәптә эшләгән һәр укытучы сыйныф сәгатьләрен үткәрү өчен, ә инде татар теле һәм әдәбияты укытучылары «Синтаксис» бүлеген өйрәткәндә, күнегүләр җыентыгын куллана ала.

Искәрмә. Фәнни эш турында кыскача мәгълүмат бирелде монда, ә тулы эш соңыннан күрсәтелә.

# ЙОСЫФ АКЧУРАНЫҢ БЕРЕНЧЕ РУС РЕВОЛЮЦИЯСЕ ЕЛЛАРЫНДА ИҖТИМАГЫЙ – СӘЯСИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Сөнгатуллина Рәзинә Нурислам кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 71нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем бюджет муниципаль учреждениесе Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Сүзем Йосыф Акчураның Беренче рус революциясе елларында иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге, ягъни аның «Иттифакъ әл-мөслимин» («Мөселманнар союзы») һәм «Мәшрутият гавамия» (кадетлар) партияләрендәге эшләве турында. Бу беренчедән, татар либераль эшлеклесен икәнен һәм Бөтенроссия мөселман халыкларының ихтыяҗларын яклаучысы икәнен күрсәтә. Акчураның кадетлар партиясенә керүе дә, алар яклы булырга чакыруы да аның тарафыннан милли ихтыяҗларны катлаулы социаль-сәяси хәлдә яклау чарасы буларак карала.

Й.Х. Акчурин, 1905–1907 еллардагы Беренче рус революциясе, сәяси эшчәнлек, милли хәрәкәт, кадетлар партиясе, Дәүләт думасы.

XIX гасырның ахыры – XX гасыр башы иҗтимагый-икътисади үзгәрешләр, социаль тетрәнүләр, милли-мәдәни яңарыш вакыты булып күрсәтелә. Ике гасыр чигендә татар җәмгыятендә зур үзгәрешләр, үсеш күзәтелә.

1905 елгы революция дулкыннары тәэсирендә Идел буе һәм Урал шәһәрләрендә мөселманнар тарафыннан җыеннар үткәрү гадәткә керә, алар гөрләп бара. Алар арасында Казандагы язгы җыен турында әйтеп китү кирәк. 1905 елның март башларында Әхмәд бай Хөсәенов, аннан соң Әхмәтҗан Сәйдәшев йортында Казандагы татарларның күренекле кешеләре җыела. Җыенда дини һәм гомуми ихтыяҗлар үзәккә куеп тикшерелә, һәр катнашкан кешегә сүз бирелә. Коръәнне татар теленә тәрҗемә итүтурында да сүз була, бик күп чыгышлар була, ләкин, бу фикерләр беркетмә буларак теркәлми.

Биредә Россия дәүләтендәге мөселман халкын берләштерү фикере үсеш ала. Март азагында Петербургта Кырым, Кавказ мөселманнары, шулай ук казак төркеме вәкилләре белән очрашу оештыру кирәклеге турында да сөйләнелә. Йосыф Акчура бу турыда Исмәгыйль Гаспринскийга (Гаспралыга) вә Гәбдерәшит Ибраһимов (Рәшит казый) Алимардан Тупчибашевка хәбәр итә. Ләкин 1905 елның язына планлаштырсалар да

барып чыкмый, ләкин Казанда үткән җыенның Русия мөселманнары арасында үзара элемтә оештырыла.

1905–1906 елларда уздырылган Мөселман съездларыныҗ эше нәтиҗәсендә милли хәрәкәт идея ягыннан яңа сыйфат ала. Бөтен Русия мөселманнары өчен бер сәяси партия – «Иттифакъ» төзелә. «Иттифакъ» ның максаты – сәяси, икътисади, дини, иҗтимагый эшләрне төзәтү һәм Русия мөселманнарын гамәли эштә берләштерү тора. Йосыф Акчура әлеге оешманың Үзәк Комитеты әгъзасы итеп сайлана.

Революциянең беренче елы узып бара. 1905 елның азагында 31 нче декабрь көнне кадетлар партиясенең Казандагы комитет әгъзалары сайлана. Исемлектә Йосыф Акчура да була.

Җыелышта конституцион-демократик партиянең 1906 елның 5–11 нче гыйнвар көннәрендә Петербургта узачак II съездына әгъзалар дә сайлана. Йосыф Акчура 10 нчы гыйнвар утырышында мөселманнарның ихтыяҗларын яклап, Казан татар кадетлары исеменнән мөрәҗәгать итә. Чыгышта мөфти җитәкчелегендә мөселман руханиларына тулы үзидарә урнаштыру; туган телдә белем алу; ил күләмендә сайлау хокукы барлык хатын-кызларга бирелгән очракта, аны мөселман хатын-кызларына да тарату һәм шәригать буенча сайлый алсыннар өчен хосусый кагыйдәләр булдыру таләпләре куела. Бу таләпләр кабул ителә. Докладчы үз фикерен дә әйтеп уза: башлангыч белемне туган телендә алучылар грамоталы, ягъни укый-яза белүчеләр дип исәпләнергә.

Кадетларның III съезды I Дәүләт думасы ачылыр алдыннан үткәрелә (21–25 нче апрель, 1906 ел). Казан кадетларына аның эшчәнлегендә катнашу өчен 5 кандидат сайларга тәкъдим ителә. 1906 елның 15 нче апрель көнне корылтай әгъзалары билгеләнә, ләкин ул исемлектә Й.Акчура булмый. Эш шунда ки, 5 нче март төнендә җирле жандармерия абруйлы партия эшлеклесен кулга ала. Шуннан соң, мөселманнар аны азат итүне сорап шәһәр хакимиятенә мөрәҗәгать итеп карыйлар. Казан губернаторы бу хакта белмәмешкә сабыша, ләкин, үз чиратында, тикшерү эшен тизләтермен, дип вәгъдә бирә. Чөнки, жандарм белән губернатор бер- берсе белән тыгыз бәйләнештә була. Шуның нәтиҗәсендә, Й.Акчура яшәгән йортта тикшерү вакытында алынган китаплар, язу-сызуларны өйрәнү сылтавы белән аны җинаяче итеп сайлаулар узып киткәнчегә кадәр диярлек төрмәдә утырталар. 8 нче апрель көнне Казан губернасының жандармерия җитәкчесе полковник Калинин йортында шикләнерлек бер әйбер дә табылмады, дип губернаторга хәбәр итсә дә, Й.Акчура 17 нче апрель көнне генә азат ителә. Шулай итеп, кулга алыну сәбәпле, Казан губернасының сайлау алды кампаниясендә һәм I Дәүләт думасы эшендә

татар либералларының күренекле вәкиле, татармөселман дөньясында танылган шәхесләрнең берсе – Йосыф Акчура катнаша алмый.

Съездда Й.Акчура кадетлар партиясе Үзәк Комитетның әгъзасы булып сайлана, ләкин соңгарак Комитетның икееллык хисабында (1905–1907 еллар) язылганча, Й.Акчура, Мөселман конституцион фиркасенә керү сәбәпле, кадетлар партиясеннән чыга (Съезды и конференции, 1997, с. 348, 503).

Казан кадетларының һәм иттифакчыларының мөнәсәбәтләренә килгәндә, Дәүләт думасына сайлаулар турында да искәрү мөһим. I һәм II Дәүләт думасына сайлаулар чорында алар бергә эш башкара, бердәм була. Мөгаен, бу үзенә күрә бер тактика була! Бәлки, бер гасырдан артык элек булган вакыйгаларны дөрес итеп бәяләр өчен милли хәрәкәтнең юлбашчысы чыгышыннан өзек ачыклык кертер. Безнең фикеребезчә, әлеге өндәмә шәхесне тирәнрәк аңларга, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген гәүдәләндерергә ярдәм итә. Җыелыш 1907 елның 9 нчы гыйнварында Казанда Яңа клуб бинасында Акчура рәислегендә уза. Монда татарлар җыела, Халык-патша рус җәмгыяте, октябристлар һәм кадетлар тарафдарлары да катнаша. Мәҗлесне Й.Акчура татар телендәге чыгыш белән ачып җибәрә.

Мәгълүм булганча, 1907 елның 3 нче июнендә Думаны тарату турында манифест чыга. Бер үк вакытта сайлаулар тәртибен үзгәртү турында закон кабул ителә. Гомумән, мондый шартларда позитив үзгәрешләргә өмет өзелә. 1907 елда Оренбургта чыккан хезмәтендә Й.Акчура төп канунның 87 нче маддәсе, сайлау канунын фәкатъ Дума гына үзгәртә алуын ассызыклый. Димәк, бу хәрәкәт канунны бозу була, дип яза автор.

Югарыда язылганнардан чыгып, шуны әйтә алабыз: җәмгыятьне либераль юнәлештә тәрәккый итү идеясен яклаучы буларак, Й.Акчура, беренче чиратта, парламентка өмет баглый, аның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге Россия мөселманнарының милли ихтыяҗларын яклауга нигезләнә. Киң җәмәгатьчелеккә киләчәк депутатлар дәүләткә вә мөселманнар өчен фәкать файдалы хезмәт кыла алырлык кешеләрдән сайланырга кирәклеген ассызыклый. Акчура, сәяси шартларга яраклашып, кадетлар белән тыгыз элемтәдә була, хәтта ки партиянең мәркәзи комитетына да әгъза буларак сайлана. «Иттифакъ эль-мөслимин»нең ныгуына үз өлешен кертә. Асылда мөселманнарның хокуклары вә мәнфәгатьләре өчен көрәшне шул рәвешле җиңү мөмкинлегенә ышана. Газиз туган халкына изге хисләрне һәрдаим йөрәгендә йөртә, сәясәтченең язмышы төрки халыкларга фидакарьләрчә хезмәт итүгә бәйләнгән була.

# ЙОСЫФ АКЧУРА: СӘЯСӘТЧЕ, ЯЗУЧЫ, МИЛЛӘТПӘРВӘР

**Хәйруллина Айсылу Расим кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган*
*71 нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе»*
*гомуми белем бюджет муниципаль учреждениесе*
*Югары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

«Үткәннәрне белмәгән халыкның киләчәге юк!» – дип әйтелә билгеле татар халык мәкалендә. Милләтебез өчен чынлап та мөһим шәхесләребезне онытсак, аларны искә алмасак – көчле милләт буларак киләчәктә яшәвебез шикле күренә. Күренекле татар мәгърифәтчеләре, педагог һәм җәмәгать эшлеклеләренә багышланган республика педагогик укуларында сезне киң җәмәгатьчелеккә аз билгеле шәхесләребезнең берсе – язучы, сәясәтче, милләтпәрвәр – Йосыф Акчура белән таныштыруны максат итеп куйдым. Халык тарихын барлауда аерым шәхесләр, аларның эшчәнлеген өйрәнү мөһим юнәлеш булып тора. Татар халкы үз җәмгыяте өчен генә түгел, төрки дөнья, шәркый дөнья, ислам дөньясы өчен хезмәт иткән дөньяви шөһрәтле шәхесләр бирә. Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдинов, Гаяз Исхакый, Йосыф Акчуралар шундыйлардан, аларның мирасы киңкырлы һәм тирән. Йосыф Акчура мирасын барлау актуаль дип уйлыйм. Хезмәтемне башкарганда мин Мәсгуд Гайнетдиннең «Йосыф Акчура», Рафик Мөхәммәтшинның «Татар зыялылары», Гаяз Исхакыйның «Мәрхүм Йосыф Акчура бәк» хезмәтләрен файдаландым.

– сөйләм үстерү дәресләрендә инновацион һәм үстерешле укыту технологияләрен куллануның максатчанлыгын һәм уңышлы булуын тикшерергә;

– ата-аналар һәм педагоглар белән хезмәттәшлек итәргә (ата-аналар җыелышлары, семинарлар, консультацияләр, буклетлар);

– инновацион һәм үстерешле укыту технологияләрен куллану өчен предмет – үсеш мохите тудыру (картотекалар, дидактик уеннар).

Проектның этаплары:

1 этап – әзерлек этабы.

– психологик-педагогик методик әдәбиятны өйрәнү;

– педагогик диагностика үткәрү;

– укучыларның сөйләмен үстерүгә юнәлтелгән чаралар циклын эшләү;

– сөйләм мөхите булдыру

**Нәтиҗәләр:** гаиләнең шөгыльләр һәм мавыгулар картасын төзү, «Туган телем – иркә гөлем», «Шәҗәрәләр – нәсел агачы» проектлары.

**2 этап – төп этап**

Укучыларда сөйләмне үстерүгә, ата-аналар, педагоглар белән үзара хезмәттәшлеккә юнәлтелгән чаралар сериясе үткәрү. Сөйләмне үстерү буенча балаларының белем бирү эшчәнлеген оештыру системасын эшләү

**Фәнни – үсеш мохитен баету:**

– әлеге тема буенча яңа күргәзмә материал булдыру;

– ата-аналар һәм педагоглар өчен кулланмалар әзерләү.

**Балалар белән эшләү:**

– лексик темаларга сөйләмне үстерү буенча перспектив пландагы дәресләр: сәламәтлек саклау технологияләре:

1. Сәламәтлекне саклау һәм стимуллаштыру технологияләре: стретчинг, ритмопластика, динамик паузалар, хәрәкәтчән һәм спорт уеннары, релаксация, эстетик юнәлештәге технологияләр, бармаклар, күзләр өчен күнегүләр, сулыш алу күнегүләре.

2. Сәламәт яшәү рәвешенә өйрәтү технологияләре: проблемалы уен (уен тренингы һәм уен терапиясе), коммуникатив уеннар, «Сәламәтлек» сериясеннән шөгыльләр, үзмассаж.

3. Коррекцион технологияләр: арттерапия, музыкаль йогынты технологияләре, экият терапиясе, төс белән тәэсир итү технологияләре.

**ТРИЗ-технологияләр** кулланып хикәянең башын, хикәянең ахырын уйлап табу, беренче заттан, тере булмаган предмет исеменнән хикәяләр уйлап табу, әкиятләр һәм төрле лексик темаларга хикәяләр иҗат итү, мәкаль буенча кечкенә күләмле хикәяләр язу, көлкеле вакыйгалар уйлап табу, тузга язмаган хикәяләр төзү. Мәгълумати технологияләрне кулланып, дәресләр, җыелышлар, семинарлар үткәрү.

**Ата-аналар белән эшләү:**

1) Консультация: «Сезнең балагыз ничек сөйләшә», «Гаилә белән уен», «Укучылар сөйләмен үстерү өчен ком терапиясе», «Предметлар ярдәмендә уен массажы».

2) Ярдәмлекләр: «Сезнең балагыз сулагай», «Сәламәтлекне саклау», «Бармаклар өчен күнегүләр».

**Укытучылар белән эшләү:**

Консультация: «ТРИЗ – укучыларның сөйләмен үстерүдә отышлы педагогик технология». «Сәламәтлек саклау технологияләре» мастер-классы

**Нәтиҗәләр:** дәресләрнең һәм дәрестән тыш чараларның авторлык эшләнмәләре, «Безнең иҗат» җыентыгын булдыру, «Татарча көндәлек» мультимедиа проектын («Татарский разговорник») эшләү.

**3 этап – йомгаклау этабы.**

1. Нәтиҗәләрне гомумиләштерү.

2. Массакүләм мәгълүмат чараларында проект нәтиҗәләре буенча мәкаләләр һәм укучыларның иҗади эшләрен бастыру.

3. Мәктәп метод берләшмәсендәге хезмәттәшләр алдында доклад белән чыгыш ясау.

4. Тәҗрибә уртаклашу максатында «Татар теле һәм әдәбиятны укытуда инновацион алымнар» семинар үткәрү.

«Сабантуй», «Нәүрүз», «Шәҗәрә», «Сөмбелә» милли бәйрәмнәре, балаларны туган илен яратырга, аның үткәне һәм бүгенгесе белән горурланырга өйрәтәләр, уңай эмоциональ халәт бирәләр. Шуңа күрә дә бу милли бәйрәмнәрне үткәрү инде гадәткә кереп бара. Көз аенда үткәрелгән «Сөмбелә» бәйрәме моның ачык мисалы.

Шәхесне рухи-әхлакый тәрбияләү әдәбияттан башка мөмкин түгел. Нәкъ менә шуңа күрә мәктәбебез традицияләренә әдәби бәйрәмнәр, китап укучылар бәйгеләре керә. Кыскасы, укучыларның рухи-әхлакый үсеше мәктәп тормышының төрле өлкәләрендә тормышка ашырыла. ФДББСын гамәлгә ашыру кысаларында бу бигрәк тә мөһим. Бәйрәмнәрдә һәм бәйгеләрдә катнашу дәресләрдә һәм укучыларның әдәби иҗатында чагылыш таба: алар үз сөйләмен баета торган иншалар, шигырьләр язалар.

Дәрестән тыш эшчәнлек – дәрес кысаларына бикләнмәгән, әмма шул ук вакытта балаларның белемен дә, зиһенен дә үстерә торган, аларның гамәли шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт мөмкинлекләренә уңай тәэсир иткән тәрбияви юнәлешнең бер алымы. Ул – уку эшчәнлеге кысаларыннан чыккан белем бирү эшчәнлеге, ләкин ул дәрестә алынган белемнәрне киңәйтүгә, тирәнәйтүгә, ныгытуга хезмәт итә.

## ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК

**Гәрәева Лилия Идрис кызы**
**Гәрәева Алия Зөфәр кызы**
*Казан шәһәре «Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл» күптелле мәгариф комплексы» дәүләт автономияле гомуми белем учреждениясе*
*Туган тел укытучы*

Дәрестән тыш эшчәнлек – федераль дәүләт белем стандартының мөһим бер өлеше. Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру ул – тәрбия һәм социальләшүгә юнәлдерелгән барлык эшчәнлек (укыту эшчәнлегеннән кала) төрләре. Дәрестән тыш эшләрнең тематикасы, юнәлешләре, төрләре бик күп. Юнәлешләре: эстетик – сәнгать юнәлеше; рухи-әхлакый юнәлеш; гомуминтеллектуаль; спорт – сәламәтләндерү юнәлеше; социаль юнәлеш. Төрләре: мәктәпнең фәнни оешмалары, экскурсияләр, бәйгеләр, түгәрәкләр, секцияләр, түгәрәк өстәлләр, диспутлар, конференцияләр, олимпиадалар, фәнни-эзләнү эшләре һ.б.

Бездә дәрестән тыш эшчәнлек рухи – әхлакый, социаль юнәлеш һәм гомуминтеллектуаль юнәлеш буенча оештырыла. Гомуминтеллектуаль юнәлеш укучыларның проект эшчәнлеген оештыруга нигезләнә.

Туган тел өлкәсендәге үзгәрешләрдән соң телгә кызыксыну кимеде. Бу сәгатьләр саны белән генә түгел, ә татар теленең җәмгыятьтә тоткан роле белән дә бәйле. Татар теле нигә кирәк? дигән уй белән мәктәпкә килгән кайбер ата-ананы, баланың татар телен өйрәнүгә булган карашын үзгәртү өчен, татар теле укытучысына аеруча да тырышлык кирәк. Туган телне белергә кирәк дип кенә, кызыксыну уятып булмый, чөнки ул үз ана телен һәр кеше белергә тиешлекне әлегә аңламаска мөмкин. Әнә шул балаларны ничек кызыксындырырга? Татар теле дәресне һәм дәрестән тыш эшне үрелдереп, бик мавыктыргыч итеп алып барырга тиеш. Милли рух тәрбияләү айлар, еллар дәвамында дәрестә генә түгел, ә дәрестән тыш чаралар да да, өйдә дә дәвам итә торган өзлексез процесс

булганда гына, моңа ирешеп була. Менә шуңа күрә ана теле укытучысы өчен укучыларның проект эшчәнлеген оештыру уңышлы. Бу юнәлештә эшләгәндә, укучы актив рәвештә уйлау, фикерләү, телне тизрәк үзләштерү эшчәнлегенә бөтен гаиләсе белән тартыла.

Бездә дәрестән тыш эшнең проект эшчәнлеге түбәндәгечә башкарыла. Укучыларны кабул иткәч, аларның мөмкинчелекләре, кызыксынуларын өйрәнеп, эш юнәлеше билгеләнә. Баланы кызыксындыру өчен башта проблемалы сорау куела. Мәсәлән, 5 сыйныф укучысы Камилла кайсы урамда яши? Ни өчен ул урам Фатих Әмирхан исеме белән аталган? Ул бу урамда яшәгәнме? Шуннан укучыда кызыксыну уяна. Кайда ул йорт? Берәр сыйныфта Ф.Әмирхан иҗаты юнәлеше булса, икенчесендә ул – туган якны өйрәнү юнәлеше һ.б. Әзләнү барышында укучыда фәнни эш итеп язарлык материал туплана. Бер төркем укучы шул нигездә фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаша, бер төркеме шул ук конференцияләрдә башка номинацияләрдә чыгыш ясый. Мәсәлән, укучылар төрле фәнни эшләр белән төрле конференцияләрдә призлы урыннар яулыйлар.

«Милләтемнең асыл затлары» проекты кысаларында үткәреләчәк чарага укучылар чирек башыннан ук әзерләнә башлыйлар. Сыйныфның яшь үзенчәлеген истә тотып, укучыларга төрле дәрәҗәдәге эшләр бирелә. Очрашуга киләсе шәхеснең я тормышы, иҗаты, эше, мавыгулары һ.б. өйрәнелә. Бу проект кысаларында язучылар, шагыйрьләр, танылган сәнгать эшлеклеләре, Г.Кариев, Г. Камал исемендәге театрлар коллективы белән очрашалар. Бу очрашулар әдәби – музыкаль композиция, түгәрәк өстәл, мастер класс формасында оештырыла. Мәсәлән, без Г.Кариев исемендәге театр артистлары белән мастер-класс үткәрдек. «Театр яктылыкка, нурга илтә» дип аталган очрашу кичәсендә кунакта Г.Камал театрлары булып сәхнә теле серләре белән бүлештеләр, укучыларның чыгышларын карап, үзләре дә музыкаль бүләкләр белән сөендерделәр. Бу проектның дәвамы булып укучыларның «Бию пәрие», «Ләйлә – Мәҗнүн» спектакльләрен карарга барулары булды. Сәхнә, театр аша укучыда милли үзаң һәм эстетик зәвык тәрбияләнә.

Тукайга багышланган проект кысаларында һәр сыйныфның Тукай тормышын, иҗатын өйрәнүне максат итеп куйдык. Сораулар, тикшерү алымнары презентацияләр әзерләнде. Югары сыйныфта Тукайның Яңа бистәдәге тормышын тикшерү максаты куелды. Бу уңайдан бистәнең Г.Тукай тормышы белән бәйләнешенә бүгенге көндә игътибар итүчеләр аз. Безнең эшнең яңалыгы да нәкъ менә шунда: кайчандыр шушы Яңа бистәнең бер гаиләсендә үзенә эти-әни җылысы тапкан Тукай эзләрен мәңгеләштерү. Тукайның ике елга якын гомеренең бәхетле елларын Яңа

бистәдә үткәрүе һәм шуны тарихка кертү тикшеренү эшебезнең актуальлеген билгели. Без тикшеренү барышында Тукайның Яңа бистәдә кайда, кайчан һәм кемнәр белән булуын өйрәндек. Дәрестән тыш эшчәнлекнең бу юнәлеше укучыга Г.Тукай буенча яңа белемнәр генә өстәп калмый, ә үзе яши торган Яңа бистә тарихыннан күпме мәгълүмат бирә, туган якка мәхәббәт тәрбияли. Эшебезнең нәтиҗәсе итеп, «Яңа бистәдә Тукай эзләре» исемле 7 минутлык видео язма төшердек. Бу видеоязма Тукайның 1891нче елда Казанга килгән Тукайның Печән базарыннан алып Яңа бистәгә кадәр булган маршрутын, андагы көнкүрешен күзалдында тота. Бу сәхнәләштерелгән өзек белән укучылар «Сәйяр» республикакүләм бәйгесендә гран-прига лаек булдылар. Шулай ук Туфан Миңнуллинның «Кулъяулык» спектакленнән өзек тә «Илхамият» бәйгесендә 1нче урынга лаек булды.

Сөйләм телен үстерүдә әлбәттә әдәби әсәрләрне өйрәнү, аларны сәхнәләштерү, сәнгатьле уку, туган телдәге әсәрләрне башка халыкларга танытырга омтылу, ягъни башка телләргә тәрҗемә итү бик зур роль уйный. Болар барысы да, дәрес кысаларында гына алып барырга мөмкин булмаган, аеруча иҗади якын килүне, күп вакыт таләп иткән хезмәтләр. Бу юнәлештә дә укучыларның мавыгып, күңел биреп өйрәнүләре, иҗат итүләре сизелә һәм төрле бәйгеләрдә чагылыш таба. «Җәлил укулары» Халыкара бәйгесендә җиңү яулау, «Илебездә, телебездә Тукай мәңгелек», «Сәләтле буын», «Илһам» яшь язучылар бәйгесендә уңышлы чыгышлар моның ачык мисаллары.

Гомуминтеллектуаль юнәлеш буенча укучылар төрле өлкәдә белемнәрен киңәйтәләр һәм интеллектуаль бәйгеләрдә көчләрен сынап карыйлар. «Шаян-ТВ» дагы «Тамчы шоу» интеллектуаль бәйгедә катнашып җиңү яулаулары да шул тырышлык һәм әлбәттә матур итеп үз туган телеңдә фикерләреңне аңлатып бирә белү нәтиҗәсе.

«Сабантуй», «Нәүрүз», «Шәҗәрә», «Сөмбелә», милли бәйрәмнәре, «Халкыбызның күңел җәүһәрләре», «Аулак өй» ләр балаларны туган илен яратырга, аның үткәне һәм бүгенгесе белән горурланырга өйрәтәләр, уңай эмоциональ халәт бирәләр. Шуңа күрә дә бу милли бәйрәмнәрне үткәрү инде гадәткә кереп бара.

Дәрестән тыш эшчәнлек – дәрес кысаларына бикләнмәгән, әмма шул ук вакытта балаларның белемен дә, зиһенен дә үстерә торган, аларның гамәли шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт мөмкинлекләренә уңай тәэсир иткән тәрбияви юнәлешнең бер алымы. Ул – уку эшчәнлеге кысаларыннан чыккан белем бирү эшчәнлеге, ләкин ул дәрестә алынган белемнәрне киңәйтүгә, тирәнәйтүгә, ныгытуга хезмәт итә.

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ФЛЭШ-КАРТАЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ АЛЫМНАРЫ

**Гильметдинова Алина Данил кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган*
*71нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе»*
*гомуми белем бюджет муниципаль учреждениесе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Тел өйрәнүдә төп бурыч – сүзлек составын тулыландыру. Әмма тел дәреслекләре авторлары, кагыйдә буларак, үзләштерү өчен шактый зур күләмдәге мәгълүмат тәкъдим итеп, яңа лексик берәмлекләрне истә калдыруга ярдәм күрсәтмиләр диярлек. Мөгаен, лексиканың «автомат» рәвештә үзләштерелүе, бу эшнең күнегүләр башкару процессында үзеннән-үзе килеп чыгуы фаразланыладыр. Ләкин, гадәттә бу гына җитми. Килеп туган проблемадан чыгуның бер юлы булып флэш-карталар куллану хезмәт итә ала.

Флэш-карталар – үз эчендә төрле мәгълүматны җыйган махсус карталар. Мәгълүмат флеш-картаның бер яки ике ягыннан да урнашкан булырга мөмкин. Мәсәлән, татар теле дәресләрендә яңа лексик берәмлекне өйрәнгәндә флэш-картаның бер ягында сүз, ә икенче ягында исә шул сүзнең рус теленә тәрҗемәсе яисә рәсем сурәтләнә ала. Әлеге метод конкрет сүз белән аның образы арасындагы турыдан-туры бәйләнешләрне билгеләргә ярдәм итә һәм моннан тыш укыту процессын кызыклы, мавыктыргыч итә. Флэш-карталарны башлангыч сыйныфта куллану уңай нәтиҗәләр бирә, чөнки нәкъ тә менә башлангыч этапта визуальләштерү аеруча мөһим роль уйный.

Башлангыч сыйныфта татар теле дәресләрендә флэш-карталар белән эшләүнең берничә алымын күрсәтергә мөмкин:

1) Укучыларга флэш-картадагы рәсем күрсәтелә, һәм нәтиҗәдә алар сүзне атарга тиеш. Бу иң гади эш алымнарының берсе.

2) Укучыларга берничә карточка күрсәтелә. Аннары шуларның берсе читкә алынып куела. Балалар нинди картаның югалганын һәм сүзне билгеләргә тиеш.

3) Тактада бер җөмлә языла. Шул җөмләдә бер сүз төшереп калдырыла һәм аның урынына флэш-карта куела. Биремне катлауландыру максатыннан берничә карточка өстәргә мөмкин.

Әлеге күнегүне эшләү барышында укучылар лексик берәмлекне билгеләүдән тыш сүзне дөрес формада бирергә тиеш. Шулай итеп, әлеге

күнегү лексиканы үзләштерергә ярдәм итү белән беррәттән грамматиканы үстерә.

4) Балалар алдына бөтен флэш-карталар өеме куела, ә тактада исә берничә хәреф языла һәм укучылар шул хәрефләрдән башланган барлык сүзләрне табарга тиеш. Бу эш алымы бигрәк тә татар теленең үзенчәлекле ү, ә, ө, һ, ң кебек авазларны истә калдыру өчен бик нәтиҗәле.

5) Балаларга сурәтле теләсә нинди флэш-карта күрсәтелә. Балалар сүзне атыйлар, аннары бу хәрефкә башланган башка сүзләрне дә әйтергә тиеш булалар.

Флеш-карталар белән эш төрләре, укытучының иҗади һәм эзләнүчән булуына карап, төрлелек белән аерылып тора. Флеш-карталарны куллануның гади төрләрен, ягъни бары визуаль материал буларак куллануны да, флеш-карталар ярдәмендә дидактик уеннар оештыруны да, мондый карточкалар ярдәмендә лексик материалны сөйләмдә куллануны тәэмин итү буенча да эш төрләрен гармоник рәвештә үреп бару әһәмиятле.

Укытучы өчен уңайлысы төрле программалар ярдәмендә тиз вакыт эчендә флеш-карталар ясаудыр, ихтимал. Шундый программаларның берсе – «Kids Flashkards». Программа белән эшләгәндә тасвтирланган объект, зат, күренеш, гамәлне реаль дөньяга якынайтып бирергә киңәш итәргә була. Укучы бу очракта өйрәнелә торган лексик берәмлекне реаль дөнья белән бәйләнешен ныграк тоя. Бу программа белән эшләгәндә сүзнең транскрипциясен дә бирү мөмкинлеге бар, бу функция программаның кыйммәтен тагын да арттыра.

Икенче бер уңайлы платформа рәвешендә Quizletны атарга була. Аның турында без эшебезнең икенче бүлегендә язып үткән идек. Рус телле балалар белән эшләүче укытучыларга без бу платформаны тәкъдим итә алабыз, чөнки ул, татар телендә эшләүче ресурс булмаса да, татар телендәге лексик берәмлекләрне өйрәнү буенча әзер карточкалар базасы булмаса да, аларны төзү мөмкинлеген бирә. Платформаның бушлай вариантында, аңлашылганча, мөмкинлекләр азрак, бары тик түләүле вариант аудиофайллар белән эшләү мөмкинлеге тудыра. Әмма бушлай вариантта да укытучы шактый файдалы күнегүләр башкара ала. Әлеге флэш-карталар дәрестә дә кулланылырга мөмкин. Шулай ук укытучы аларны укучыларга өйдә лексик күнекмәләрне ныгыту өчен дә тәкъдим итә ала.

Йомгаклап шуны искәртик: флэш-карталар уку-укыту сыйфатын бермә-бер күтәрә, функциональ грамоталылыкка акцент ясап, традицион белем бирү кысаларын киңәйтә.

# ФДББС ШАРТЛАРЫНДА ЭЗЛӘНҮ – ТИКШЕРЕНҮ ЭШЧӘНЛЕГЕН ОЕШТЫРУ

**Закиров Айдар Миңлекәшиф улы**
**Мансуров Алмаз Илдар улы**
*МАББУ «7нче лицей-интернат»*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

Укыту системасы күпмедер дәрәҗәдә үзгәрешләр кичерде. ФДББС килеп керде, шуңа бәйле рәвештә безнең эшчәнлегебез дә башкачарак алып барыла. Элеге эшебездә, үзебезнең эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенең үзенчәлекләре турында уртаклашасы килде. Әлеге эшебезнең актуальлеген безнең бу юнәлештә куйган хезмәтебез һәм шуның нигезендә ирешелгән нәтиҗәләр билгели.

Шулай итеп, федераль белем бирү дәүләт стандартларын өйрәнеп чыкканнан соң, без үз алдыбызга андагы бик күп таләпләр арасыннан, эзләнү-тикшеренү эшенә кагылышлы берничә таләпне аерып чыгардык.

Беренчедән, эзләнү-тикшеренү эше конкрет булырга тиеш. Аның конкрет объекты, без күрә алырдай, тотып карый алырдай, ишетә алырдай берәр предмет, образ, халәт һ.б. булырга тиеш.

Икенчедән, ул һәрвакыт нинди дә булса социаль әһәмияткә ия. Әһәмиятле эш булмаса, укучыларның бу эш белән шөгыльләнәсе килмәс иде.

Өченчедән, мәгълүмати, гамәли проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән. Мәсәлән, Болак күперләренең тарихын, килеп чыгышын, архитектур үзенчәлекләрен, берәр шәхес турында, ниндидер тарихи объект турында ялгыш фикер булу – ул мәгълүмати проблема. Җәмгыятьтә капма-каршы фикерләрне дә шундый проблемалар рәтенә кертә алабыз. Аларны хәл итү, тикшеренү эше вакытында төгәллек кертү безнең максат булып тора.

Дүртенче таләп – тикшеренүләр үткәрү. ФББДС укучының тикшеренү үткәрүен таләп итеп куя. Ул нәрсәне дә булса өйрәнергә, тотып карарга, ишетергә, аның турында мәгълүмат тупларга тиеш.

Үзебез дә сизмәстән, киләсе таләпкә дә күчтек. Мәгълүмат эзләү төрле-төрле булырга мөмкин, ул интернетта, китапханәдә, я булмаса кемнәрдән дә булса сораштыру һ.б. Мәгълүмат эзләү ул бер фән буенча (әдәбият яки туган тел) буенча гына бармый, төрле фәннәрне дә үз эченә ала. Бу – предметара бәйләнешләрне барлыкка китерә Мәсәлән, Һади Такташны өйрәнгәндә, география, тарихка һәм башка фәннәргә кагылып китәргә мөмкин.

Эшне тәкъдим итү – эшне яклау, күрсәтү рәвешендә башкарыла. Укучы үзенең эшен тәкъдим итә белергә, аның әһәмиятен аңларга тиеш. Эшне яклаганда, ул эшенең бөтен үзенчәлекләрен белергә, аны ни өчен эшләгәнен аңларга тиеш. Гади генә итеп әйткәндә, нинди сорау гына бирсәң дә, җавап бирә белүе шарт.

• Ни өчен без нәкъ менә шушы таләпләрне аерып чыгардык соң? ФДББС таләп иткәнчә, алар баланы актив эшчәнлеккә тарта. Шушы тәртиптә эшне оештырсак, бала үзе белем ала дигән сүз бу. Ә баланы актив эшчәнлеккә тарту өчен нәрсәләр кирәк? Кызыклы тема кирәк. Тема балада кызыксыну уятмаса, ул аның белән шөгыльләнмәячәк. Мисал өчен, укучылар Горький паркындагы Һади Такташның кабер ташын, Рөстәм Миңнехановның малае каберен күреп кайттылар. Сорау туа: «Ни өчен элек зират булган, ә хәзер – парк? Парк уртасында кеше күмелгәнме?». Шуннан чыгып, укучыга зиратларга багышлап тема тәкъдим итәргә була. Безнең Татар зираты турында «Мәңгелеккә күчкән тарих» дигән эшебез бар инде. Тема үзенчәлекле. Анда гадәти булмаган (Рөстәм Нургали улы Миңнехановның малаеның паркка күмелүе) элемент бар.

• Тема чагыштырмача тиз үтәлергә тиеш. Озакка сузылган эшкә карата кызыксыну кими, нәтиҗәсе дә начар була.

• Тема яшь үзенчәлекләренә туры килсен. Мәсәлән, Такташның мәхәббәт лирикасын, конкрет алсак, «Мәхәббәт тәүбә» сен 7 нче сыйныф укучысына бирсәк, анда кызны алдауларын, аның ана булуын ул аңлап бетермәс, яки дөрес аңламас. Икенче мисал, 11 нче сыйныф укучысы тылсымлы әкиятләрне өйрәнсә, аңа да бу эш бик кызык булмас кебек.

• Теләкләр мөмкинлекләргә туры килүе шарт. Без һәрвакыт үзебез күрә алырдай, үзебез бара алырдай, тикшерә алырдай әйберне өйрәнәбез. Ничек кенә теләсәк тә, Париждагы Эйфель манарасын өйрәнә алмыйбыз, чөнки мөмкинлекләребез юк.

• Эшне сузмаска, тема табылуга башларга кирәк. Балада нәрсәгә дә булса кызыксыну туса, аны борып җибәрергә ярамый, тыгыз эш графигына карамастан аның белән шөгыльләнергә кирәк.

Баланы актив эшчәнлеккә тарту өчен төп кирәк әйбер – аның кызыксынуы икәнен аңладык. Кызыксынуны ничек уятырга соң?

Нәрсәгә дә булса игътибар, кызыксыну өч әйбер: күрү, ишетү һәм тактиль органнар ярдәмендә формалаша. Тактиль органнар дип үзебезне шул мөхиттә тою, әйләнә-тирәне кешедә булган барлык тоемлаулар белән кабул итүне атыйбыз.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, әгәр дә мәгълүматны кабул итүне һәм кызыксынуны шартлы рәвештә «М» хәрефе дип алсак, ишетү органнары

– М*1, күрү органнары – М*5, тактиль органнар М*13 булыр иде. Ягъни, тактиль органнар мәгълүматны 13 тапкырга күбрәк кабул итә. Бу алар ярдәмендә кызыксыну уяту җиңелрәк һәм эффектлырак була дигән сүз. Бу алымны шартлы рәвештә күреп өйрәнү (истә калдыру) методы дип атыйбыз һәм шуны кулланырга тырышабыз.

Гомумиләштереп әйткәндә, ФББДС дөрес аңлау, эзләнү-тикшеренү эшләрен тиешенчә һәм кызыклы итеп оештырырга ярдәм итә.

## УКУЧЫЛАРНЫҢ СӘНГАТЬЛЕ СӨЙЛӘМЕНӘ ИРЕШҮ ЮЛЛАРЫ

**Захарова Альбина Алексей кызы**
*Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы*
*Осиново бистәсенең «В.В.Карпов исемендәге лицей»*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*Туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Педагогик эшчәнлек – аңлы һәм максатлы рәвештә алып барыла торган тәрбияви күренеш, һәм ул җәмгыятьнең иң мөһим бурычларның берсе. Без әнә шундый бурычларны куйган җәмгыятьтә яшибез. Татар теле һәм әдәбияты укытучысына бурычлар икеләтә арта. Беренчедән, тел мөгаллиме балаларга белем бирә, тәрбия кыла; икенчедән, туган тел аша яшь буынга халыкның бай рухи мәдәниятен, аның дөньяны танып белүен, идеалларын, халыкның озак еллар буе тупланган белемен һәм тормыш тәҗрибәсен тапшыра.

Әйе, дөрестән дә, туган телне һәм әдәбиятны укыту кебек җаваплы фән юктыр ул. Ник дисәң, без, тел мөгаллимнәре алдында, белем һәм күнекмә бирүдән тыш, туган теленә, халкына олы һәм саф мәхәббәт хисен тәрбияләү, гореф-гадәтләрен өйрәтү, милли үзаң, иман-әхлак сеңдерү бурычы да тора. Минемчә, һәр татар теле һәм әдәбияты укытучысының төп бурычы – укучыда эчке матурлыкта омтылыш тәрбияләү, әйләнә-тирә мохиткә, дөньядагы төрле вакыйгаларга дөрес бәя бирү. Аралаша белүнең төп шарты – бала күңелендә китапка мәхәббәт тәрбияләү.

Тел дәресләрен күбрәк проблемалы, иҗади эзләнү – тикшеренү рәвешендә үткәрергә тырышу да эзсез калмый: укучыларымның кыю үз фикерләре, үз тормыш позицияләре сиздерә.

Сүз байлыгын арттыру һәм әдәби телдә сөйләргә өйрәтү – укучылар сөйләмен үстерүдәге икенче юнәлеш. Өченче юнәлеш – фикерне телдән һәм язма рәвештә әйтә белергә өйрәтү.

Әдәби әсәр белән танышкач, сөйләм үстерү максатыннан, төп геройга яки укучының үзенә ошаган образга хат язу алымын да кулланам.

Һәркемгә билгеле: һәр сыйныфта материал үзләштерүдә төрле кыенлыклар кичергән укучылар бар. Шуңа күрә дәрескә биремнәр әзерләгәндә укучыларның индивидуаль үзенчәлекләрен истә тотам.

Интернет аша коллегаларым белән эш тәҗрибәсе белән дә уртаклашырга онытмыйм. Укучыларның һәм үземнең эзләнү эшләрен инфоурок, nsportal сайтларында урнаштыра барам.

Җанлы уку – тасвири уку. Монда укылган әсәрдәге хис – кайгымы, көенеч вә шатлыкмы, башкамы – укучының йөрәгенә керә, йөрәгеннән тавышына килә: аның тавышы күз яшьсез елый, кылычсыз кисә. Икенче төрле әйткәндә, тасвири уку – әсәрдән алынган тәэсирнең тавыш белән бирелүе димәктер.

Галимҗан Ибраһимовның әйткән сүзләре нәрсә турында?

Тәэсирле сөйләм, нәфис сүз, ораторлык осталыгын бер ноктага төйнәп өйрәнә торган махсус фән? Димәк, бу фән – риторика.

Укучыларның сәнгатьле сөйләменәирешү юллары.

**Дикция**. Әдәби әсәрне укыганда һәр авазның ачык әйтелүе. Дикцияне халык авыз иҗаты аша көйләргә була. Әдәби сөйләмне ихластан тыңларга өйрәтә. Мәсәлән:

Дару белән өч шешә,
Шешә бавын теш чишә,
Шешә чишсәң, теш шешә.

**Логик басым.** Контекст яки ситуация таләбеннан чыгып, басымлы сузыкның көчен арттыру аша берәр сүзнең басымын көчәйтү юлы белән барлыкка килә. Логик басымны үзгәртеп җөмләне укырга. *Итегеңне салма, әниеңнең сүзен тыңла.*

**Интонация**

Сөйләмнең ритмик-мелодик агы, тавыш хәрәкәте ике аспекты бар.

1. Коммуникатив аспект:

а) сөйләм агымын оештыру һәм кисакләргә бүлү функциясе. Бу сөйләмне синтагмаларга, җөмләләргә, фразаларга бүлү;

б) әйтелеш типларын формалаштыру (хикәя, сорау, өндәү)

в) интонация җөмләне актуаль кисәкләргә бүлүдә катнаша.

2. Эмоциональ аспект – сөйләүченең эмоциональ халәтен, аның тыңлаучыга ничек тәэсир итү теләген белдерү, интонациянең модельлелек белдерүе (шатлану, борчылу, курку һ.б. төсмерләр белән әйтелә ала). Җөмләне төрле интонация белән укыгыз. *Матур итеп сөйләшә белгән кеше матур итеп уйлый белә.* (Фәнис Яруллин)

**Күзаллау**

«Гармунчы аю белән җырчы маймыл» (Ф. Кәрим)

**Мимика, жест**

Гәүдә тотышы, йөз, мимика ярдәмендә. «Безме, безме, без булдырдык!» – дигән җөмләне горурлык хисе белән әйтегез

**Рефлексия**

Сәнгатьле сөйләмгә өйрәткәндә, нинди алымнар мөһим? (Дикция, логик басым, интонация, күзаллау, мимика, жест)

Кеше үзенең эшләгән эше белән матур, диләр. Ә безнең эшебезнең нәтиҗәсе – һәр баланың бүгенге катлаулы чорда үз юлын табуы. Алар иманлы, шәфкатьле, миһербанлы икән, димәк хезмәтебезгә яхшы бәя куярга мөмкин. Эшебезнең нәтиҗәсе никадәр матур булса, киләчәгебез дә шулкадәр якты дигән сүз, чөнки балалар – безнең киләчәгебез.

## МӘГЪЛҮМАТИ ҖӘМГЫЯТЬТӘ МЕДИАКУЛЬТУРА

**Мәҗитова Айгөл Локман кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*«23 нче лицей» гомуми белем*
*бюджет муниципаль учреждениесе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Заманча җәмгыятьнең эшчәнлеген анализлаганнан соң, медиа өлкәсендә технологик алгарышлар һәм динамик модификацияләр бара, дип кыю рәвештә әйтергә була. Технологик яңарышларның әһәмиятен аңлап, галимнәр һәм практиклар рухи өлкә үсешенең әһәмияте турында да еш сүз алып бара башладылар. Аерым кеше һәм дөнья медиакультурасын формалаштыру мөһимлеге барлыкка килде.

Соңгы тулы булмаган унъеллыкта россиялеләр тарафыннан кәгазь басмаларның барлык төрләрен укуга, радио һәм телевидение куллануга бирелгән вакыт өлеше шактый кимегән, интернет-массакүләм мәгълүмат чараларын, кәрәзле телефоннарны куллануга тотылган вакыт уннарча тапкыр арткан.

Оксфорд университеты галимнәре үткәргән тикшеренү буенча 50 миллион кулланучыны җәлеп итү өчен, телефон компанияләренә 75 ел вакыт кирәк булган, телевидениегә – 38, ә интернетка барлыгы 4 ел. Фейсбук бер ел эчендә 200 млн кулланучыны үзенә җыйды. Ютюб каналын ай саен бер миллиардтан артык кулланучылар карый, ике миллиард кеше төрле социаль челтәрләрдә аккаунт булдырган.

Динамик рәвештә үзгәрүче медиагадәтләр медиа куллануны шәхсиләндерүгә китерә, «санлы буын», «челтәргә кертелгән» тамашачылар барлыкка килүен раслый. Дөньяның яңа күренешләре, аның үзгәрүчәнлеге һәм күп каналлылыгы турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Димәк, без мәгълүмат артык күп булган шартларда яшәргә өйрәнергә тиеш. Медиа агымнарында ориентлаша белү, мәгълүматны анализлау һәм дөрес бәяләү, массмедиа белән диалог күнекмәләре булдыру, мәгълүмат чаралары ягыннан манипуляцияләнүне таный белү- медиа культураның база категорияләре булып торырга тиеш.

Медиакультура (media culture), үз чиратында, медиа өлкәсендә матди һәм интеллектуаль кыйммәтләр җыелмасы, шулай ук аларны яңадан торгызу һәм социумда эшләү буенча тарихи билгеле бер системасы булып тора.

Мәгълүмат куллану культурасын формалаштыру ул массакүләм мәгълүмат чараларының тел үзенчәлекләрен аңлау һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән аралашу барышында критик фикерләүне үстерү, теге яки бу проблемага әзерлек вакытында өстәмә мәгълүмат куллану мөмкинлекләрен дә аңлауны үз эченә ала. Бу хәзерге мәктәп укучысының медиакультурасын формалаштыруның кирәклеген һәм аерым ролен билгели.

Укытучылар өчен дә дәресләрдә, дәрестән тыш эштә, дистанцион укыту вакытында файдалану өчен бик күп сайтлар, платформалар булдырылган. Аларда аерым фәннәр буенча мәгълүмат тупланган. Ләкин бу платформалар медиакиңлекнең бик аз өлешен генә алып тора. Безнең укучыларыбыз кино, видео, интернет, интернет-бергәлекләр, блоглар һәм сайтлардан башка яши алмый. Бу белем һәм тәрбия бирү максатларын тормышка ашыру һәм баланың үз-үзен билгеләү нигезләре буларак медиакультураны формалаштыру өчен педагогик хезмәттәшлек процессына мөмкинлек бирә. Медиакиңлек мөмкинлекләрен кулланырга, яшүсмерләр белән күмәк иҗади белем бирү процессының актив катнашучылары булып китәргә этәргеч булып тора.Заманның тагын бер глобаль проблемасы – балаларның әдәби һәм башка китап укуга теләге кискен кимүе. Укытучылар үз медиаконтетлары ярдәмендә укучыларны нәкъ менә әдәбиятка, китап укуга кызыксынуларын арттыра алалар. Медианы булдыру һәм куллану процессы ул да текстлар белән тирән һәм җитди эш булып тора, бары тик башка форматта.

Мин үзем социаль челтәрләрдә үз аккаунтларымны күптән булдырдым. Вконтакте һәм Инстаграмм челтәрләре аша бик актив рәвештә төрле мәгълүмат белән уртаклашып барам. ВКонтакте челтәре дә, Инстаграмм

бите дә https://belem.ru/ сайты, Татнетны үстерү фонды игълан иткән бәйгеләр өчен мәйданчык булып тора.

Берничә ел рәттән #әдәбимарафон бәйгесендә мин дә катнашып киләм. Бу бәйге кысаларында мин татар шагыйрьләренең әсәрләреннән өзекләрне Вконтакте битендә https://vk.com/id17143221 яктыртып барам. Һәр бәйге аерым бер шәхескә багышлана: Марат Кәбиров, Роберт Миңнуллин, Гөлүсә Батталова, Әнгам Атнабаев, Зөлфәт, Рифат Сәлах һәм башкалар. Бу материаллардан дәресләрдә, сыйныф сәгатьләрендә еш файдаланам. Әсәрләр тулысынча түгел, ә өзек белән бирелә, бу, үз чиратында, укучыларны кызыксындыру өчен бик уңышлы алым. Эшнең дәвамы итеп, укучылар бирелгән әсәрне табалар, авторның башка шигырьләре белән танышалар, сәнгатьле уку өстендә эшлиләр. Авторның башка әсәррләретабу өчен бу очракта Хештеглар ярдәм итә. Өзекләр үзем төшергән фотолар белән дә тулыландырылып барам. Темасына туры килгән җырлар да өстим. Куелган фотоларның да эстетик яктан тәрбияви әһәмимяте бар дип уйлыйм, чөнки әсәрдә чагылыш тапкан хисләрне ачып бирерлек фотолар беркетергә тырышам. Укучыларым арасында да фото белән кызыксынучылар күп.

Лицей укучыларын да бәйге кысаларында урнаштырылган әсәрләрне уку белән генә чикләнмичә, ә бәлки үзләренә дә катнашып карау өчен мөмкинлекләр тудырдык. Лицей эчендә үз бәйгебезне оештырып үттек. Теләк белдереп катнашучы укучылар хәйран күп җыелды. 21 көн дәвамында катнашучыларны билгеләп үттек һәм бүләкләр тапшырдык. Дөньякүләм әдәби марафон мәйданчыгына катнашып китәргә әзер укучыларыбыз да бар бүгенге көндә.

Вконтакте челтәрендә яктыртылып килгән тагын бер дөнькүләм онлайн-бәйге – «Авылым гүзәллеге». Авыл тарихы, авылның бүгенге хәле, проблемаларына игътибар юнәлтү йөзеннән һәм татар телендә сыйфатлы итеп язылган мәкаләләрне арттыру максатыннан эшләнгән бәйге булды ул.

Татар авыллары үзенең тырыш халкы, көнкүреше, табигате, шәхесләре һәм тарихи һәйкәлләре белән горурлана ала. Әмма күбебез еш кына тиешенчә үз туган ягыбызның матурлыгы белән соклана, аның табигатен кадерли, кешеләрен хөрмәт итә белмибез. Туган ягыбызны кадерләргә, табигатен сакларга, авылларны яхшыртырга, аннан чыккан шәхесләрне белергә һәм хөрмәт итәргә кирәк. «Авылым гүзәллеге» (#авылымгүзәллеге) проекты нәкъ менә шушы максатлардан чыгып 2020 елдан башлап елга бер мәртәбә яз аенда оештырыла. Проектта татар авы-

лында туып үскән һәм, Татарстанда гына түгел, дөньяның төрле почмагында яшәүче интернет-кулланучылар катнаша ала. Яшь чикләре: 13+.

21 көн дәвамында мәкалә, фото, аудио һәм видеоматериаллар урнаштырып, үземне финалистлар рәтендә күрү бәхетенә ирештем. Бу материаллар, шулай ук, дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда куллану өчен файдалы.

Инстаграм битендә https://www.instagram.com/mazitova16/ дә https://belem.ru/ бәйгеләре чагылыш таба. Бу биттә мин рецептлар белән уртаклашам. Рецептларны бары тик татар телендә генә урнаштырам. Күптән түгел уздырылган #тәмлемарафон бәйгесендә катнашып, финалистлар рәтенә уздым. Хәзерге көндә бәйгенең йомгаклау тантанасын көтәбез. Бу эшем дә очраклы түгел. Татар халкының һәм башка халыкларның милли ризыклары белән таныштыру йөзеннән башлап кителгән эш булды ул. Рус телендә мондый форматта бирелгән мәгълүмат күп, ләкин чиста татар телендә язылган битләр аз иде мин башлап җибәргән вакытта. Шулай ук, һәр рецептны үзем төшергән фотолар белән бизәп барам.

Инстаграм бите ике ел Дөньякүләм «Белем җәүһәрләре» татар интернет-проектлары бәйгесенең финалисты булды.

Укытучылар да медиакиңлек мөмкинлекләреннән ешрак файдалансыннар иде, дигән фикердә калам мин. Чөнки бу киңлекне тәрбияви контент белән тулыландыру безнең дә бурыч.

## ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК – БЕЛЕМ БИРҮ ПРОЦЕССЫНЫҢ АЕРЫЛГЫСЫЗ ӨЛЕШЕ

**Низамиева Альфинур Нуртдиновна**
*Татарстан Биектау муниципаль районы*
*Айбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Эшнең максаты: дәрестән тыш эшчәнлекнең актуальлеген күрсәтү, төрләре белән таныштыру

Бурычлар: дәрестән тыш эшчәнлекнең укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә әһәмиятен раслау.

Бурычларның актуальлеге: туган телләрне куллану һәм үстерүнең милләтне саклаучы фактор булганлыгын ассызыклау.

Бурычларның методик чишелеше: күп еллык эш тәҗрибәмә анализ ясау, алдагы эшкә бурычлар кую.

Безнең туган телебез – матур-матур романнар иҗат итәргә киң мөмкинлекләре булган стилистик яктан бай тел. Туган тел туган җир кебек кадерле һәм газиз, ул – кеше күңелендә иң нечкә, мөкатдәс хисләр, күркәм сыйфатлар тәрбияләүнең иң куәтле чарасы. Ул – әби-бабай, әткәй-әнкәй теле, дөньяга күзең ачылырга, әйләнә-тирәне танып белергә, чиксез матурлыкларны аңларга-тоярга ярдәм итә торган тел. Үз телеңне белмәү ул – чын мәгънәсендә маңкортлык, бай культура мирасын аңлаудан читләшү, тормыштан төшеп калу дигән сүз. Туган телне санламау – ул кимчелек кенә түгел, зур мәхрүмлек тә.

Татар мәктәбендә 40 елдан артык укытып (миңа башлангыч сыйныфларда да укытырга туры килде), мин үземә кайбер нәтиҗәләр ясадым. Билгеле, мин класс җитәкчесе дә булдым. Тәрбия чаралары 80 нче елларда партия идеологиясе белән бәйле булса, 90 нчы еллардан башлап, укучы балаларны халык педагогикасына нигезләнеп тәрбияләдем. Төп корал – безнең туган телебез. Һәр бала туган телендә язылган китаплары, халыкның тәрбия тәҗрибәләре, милли сәнгате, гореф-гадәтләре, традицияләре белән тәрбияләнергә тиеш.

Татар теле синонимнарга байлыгы ягыннан бары алман теленнән генә калыша. Алман телендә 25 мең синонимик оя булса, татар телендә – 9 мең, рус телендә – 8 мең оя. Халкымның теле йомшак, назлы, нечкә, тәрҗемәчеләр тәмле дип тә әйтәләр.

1990 нчы елда республикабыз суверенлык алгач, матур татар телебез дәүләт теле дип закон белән беркетелде. Ләкин дәүләт теле буларак, татар телендә нинди эш кәгазьләре язылды соң, дәүләт күләмендә нинди утырышларда кулланылды? Депутатларыбыз Т.Миңнуллин, Р.Вәлиев, А.Зыятдинов, Ф.Бәйрәмовалардан башка кем татар телендә чыгыш ясады? 2017 нче елның көзе актык өметләребезне дә юкка чыгара язды. Менә шундый шартларда телебезне ничек саклап калырга соң? Шуңа күрә дә татар теле укытучысы – мәктәптә иң күп эшләүче кеше, чөнки без гомер-гомергә туган телебезне саклап, яклап яшибез, эшлибез. 2017 нче елгы вәзгыятьтән соң без, Тукайча әйтсәк, «күкрәк биреп каршы торам», дип, телебезне саклау өчен көрәшкә күтәрелдек. Дәресләр кыскарды, дип тормадык, дәрестән тыш чараларны тагын да күбрәк уздыра башладык. Сәләтле укучылар белән дәрестә эшләп өлгереп булмый, шуңа күрә дәрестән тыш бик күп шөгыльләнергә кирәк. Укучыларда туган тел дәресләренә кызыксыну уятуда, өстәмә белем бирүдә «Сәләт» иҗтимагый фонды чыгарган электрон әсбап бик зур роль уйнады һәм уйный. 2006-2007 нче уку елында ук мин 5 нче сыйныф укучыларын электрон татар теле дәреслеге белән эшләргә өйрәттем. 2007-2008 нче

уку елында мәктәптә узган семинарда районның татар теле укытучыларын бу дәреслек белән таныштырдым. Электрон уку-укыту ярдәмлегенең төп өстенлеге – компьютер технологияләренең мәктәптә белем бирүнең алдынгы юнәлешләре һәм традицияләре белән табигый кушылуы. Бу ярдәмлек уку-укыту процессын тагын да кызыклырак, мавыктыргычрак һәм тәэсирлерәк итә. 2008 нче елда тагын бер электрон дәреслек дөнья күрде. Монысы 5-11 нче сыйныфларда татар теле дәресләрен үткәрергә, сәләтле укучылар белән эшләргә ярдәм итә. Дәреслектә теория дә, интерактив бирем-күнегүләр дә, катлаулы тест сораулары да бар. Гадәти дәреслектә булмаган материаллар, укучының белемен тирәнәйтә торган мәгълүматлар искиткеч әйбәт итеп бирелгән.

Сәләтле укучыларга элек өстәмә материалларны табу бик җайлы түгел иде. Хәзер бераз эшләр җиңеләйде. «Хәзерге татар әдәби теле» китабында бирелгән күнегү-биремнәр, Н.В.Максимовның «Татар теленнән тестлар» ның элеккеге һәм яңа вариантлары, «Фонетика, морфология», «Гади җөмлә синтаксисы», «Кушма җөмлә синтаксисы» ярдәмлекләре, Ф.С.Сафиуллина һәм Г.Ә.Нәбиуллинаның «Синтаксистан тестлар» әсбабы, Галиуллина Г.Р.ның лексикология буенча хезмәтләре искиткеч әйбәт. КФУ ның татар теле галимнәре әзерләп чыгарган «Олимпиадага ничек әзерләнергә?» дип исемләнгән электрон ярдәмлеге дә көчле укучылар белән шөгыльләнү өчен бик кирәкле. Сәләтле укучыларым район, республика, Халыкара олимпиадаларда җиңделәр, призерлар булдылар.

Укучыларда татар теленә, халкыбызның рухи-әхлакый байлыгына мәхәббәт тәрбияләүдә класстан тыш матур әдәбият китапларын укуның да әһәмияте зур. «Татар теленең дәрәҗәсен күтәрү, аны аралашу теле баскычыннан күпләр өчен әдәби, фәнни телгә әйләндерү, укучыларга халыкның рухи хәзинәләрен, милли сәнгатьнең матурлыгын, мәдәни байлыкны күрсәтеп, шуларга соклану, халкың белән горурлану хисләре тәрбияләү өчен иң туры, кыска юлларның берсе аның әдәбиятын уку, ярату, өйрәнү икәнлеге берәүдә дә шик уятмый», – дип язды галимәбез Д.Заһидуллина да. Укучыга тәрбияви әһәмияткә ия булган китап тәкъдим итә белергә кирәк, компьютер, интернет, гаджетлар заманында бигрәк тә. Ә татар әдәбиятында дөрес әхлак формалаштыруга, шәхес тәрбияләүгә багышланган әдәби әсәрләр бихисап. Мәсәлән, бу эшне мин 5 нче сыйныфтан башлыйм. Дәрестән тыш әкиятләр укыту, Г.Тукай, А.Алиш, Ф.Яруллин, Г.Гыйльманов һәм яшь язучыларның балалар өчен төрле әкият, хикәяләрен тәкъдим итү отышлы. Т.Миңнуллинның «Авыл эте Акбай» пьесасының «Акбай һәм Кыш бабай», «Акбай, Тәмлетамак һәм Этбүрләр», «Акбай нигә күңелсез?» һ.б. кебек дәвамын балалар яратып

укыйлар. 5 нче сыйныф укучыларына дәрестән тыш уку дәфтәре башлату зур әһәмияткә ия, мин аларга дәфтәр тотышын аңлатам, үрнәк дәфтәрләр күрсәтәм. Бу эшне һәр класста искә төшереп тору, үрнәк дәфтәрләр күрсәтү бик файдалы. Китап укыган баланың өй эшләре дә бик иҗади, китаплардан файдаланып башкарыла.

Дәрестән тыш уздырылган чараларның да китапка игътибар, кызыксыну тәрбияләүдә әһәмияте зур, кичәләрдә язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән якыннанрак танышу мөмкинлеге туа. Элегрәк һәр елны диярлек укучыларны «Туган тел» бәйрәменә, ягъни «Шигырь бәйрәме» нә алып барырга тырыштым. Хәзер андый мөмкинлек юк, шуңа күрә «Шигырь бәйрәме»н мәктәптә карауны оештырам. «Китап биргән тәрбияне башка бернәрсә дә бирә алмый», – дип әйтергә ярата иде укытучым Фазлыев Тимергали абый. Милли китап – халыкның көзгесе. Анда милләтнең меңләгән еллар дәверендә үткән тәҗрибәсе һәм уңышлары, ачыш һәм табышлары, хыял һәм өметләре, кайгы һәм хәсрәтләре – бөтен тарихы чагылыш тапкан. Шуңа күрә китапка игътибарны киметмик, киресенчә, арттырыйк. Укучыларымны үзем белән бергә «Әдәби марафон»да катнаштырам. Укучылар китапханәгә кайткан өр-яңа китапларны алып укыйлар. Соңгы елларда дәрестән тыш чараларны төрләндереп, Татарстан Яңа Гасыр (ТНВ)да барган тапшырулар, мәсәлән, «Башваткыч», «Тәрҗемә ит», «Тамчы-шау», «Әдәби хәзинә» һәм башка тапшырулар форматында үткәрәбез. Укучылар бу чараларны аеруча яраталар, катнашалар, яңа технологияләрне теләп өйрәнәләр. Район, республика буенча уздырыла торган конкурслар да яңача, заман таләпләренә туры китереп оештырыла. Без бу бәйгеләрдә дә актив катнашабыз, җиңәбез, призлы урыннар алабыз. Мәсәлән, видеороликлар, видеофильмнар, видеофайллар, презентацияләр, буктрейлерлар бәйгесе, компьютер технологиясе кулланылган башка конкурслар.

Укучыларда татар халкына, аның теленә, әдәбиятына, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә, матур традицияләренә мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләү максатыннан «Халык педагогикасы», «Татар китабы», «Кызыклы грамматика», «Оста куллар» түгәрәкләренең программаларын үзем төзеп, занятиеләр уздырдым, уздырам. Түгәрәккә йөргән укучылар белән дәрестән тыш кызыклы чаралар әзерлибез. Бу чаралар мәктәптә генә түгел, авыл мәдәният йортларында уза. Язучыларга багышланган, Халыкара Туган тел көненә карата, бөекләребез Г.Тукай, М.Җәлил, С.Сәйдәшев, Б.Урманче, Н.Исәнбәт иҗаты буенча үткәрелгән мероприятиеләр укучылар күңелендә билгеле бер эз калдыра, тәрбияли.

Конкурс-бәйгеләрдә, конференцияләрдә, төрле укуларда мин үзем дә бик актив катнашам, газеталарга мәкаләләр язам, җыентыкларда хезмәтләрем басыла. Укытучы үзен шулай камилләштермәсә, ул тормыштан артта калачак. «Әдәби марафон»ның беренчесеннән үк катнашып киләм, файдасын сизәм, кирәклеген беләм. Дөрес, вакыт та, ихтыяр көче дә сорый торган эш. 2021 нче ел Туган телләр елы дип игълан ителгәч, мин укучылар, укытучылар, әти-әниләр белән авыл мәдәният йортында елны тантаналы ачуга багышланган парламент дәресе уздырдым. Искиткеч эчтәлекле, кызыклы, файдалы булды бу очрашу. Эшкәртмәсен район конкурсына җибәрдем, өченче урынга лаек булдым. 2022 нче ел Россия халыкларының мәдәни мирас елы дип игълан ителде. Татар халкының матди һәм матди булмаган мәдәни мирасы турында чыгышым әзер, укучылар, укытучылар, әти-әниләр белән шул турыда зур чара оештырырга уйлыйм.

Нәтиҗәләр: Югалтканнан соң гына без әйбернең кадерен беләбез. Мәктәпләрдә татар теле дәресләре кимегәч, татар кешесенең күзе ачылды, югыйсә без татар халкының кыйммәтле мирасына карата ваемсызлана башлаганбыз. Үзебезне хөрмәт иттерергә теләсәк, рухи һәм материаль казанышларыбызны сакларга, милли мәгарифебезне үстерергә тиешбез. Бергәләп тотынсак, иншалла, телебез югалмас, милләтебез яшәр, күпне күргән халкым бу юлы да сынауларга бирешмәс.

**Кулланылган әдәбият**


1. «Ватаным Татарстан», 2016, №105, 2017, №20
2. Заһидуллина Д. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2004. –367 б.
3. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. – Казан: Тат. кит.нәшрияты. – 1997. – Б. 21-24.
4. Җәләлиев Ш.Ш. Милли тәрбия нигезләре. – 2003. – Б. 99-105.
5. Көч һәм рух тамырлары. Әдәплелек дәресләре //5-11 сыйныфлар өчен хрестоматия. – 2000. – Б. 6.
6. Кәримуллин Ә. Китап дөньясына сәяхәт. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979
7. Китап бәйрәме. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2003. –95 б.
8. «Мәгариф» журналы. 2014, №5
9. Фәтхелисламов Ф.Н. Уйларның йөртик изгесен. – Казан: Матбугат йорты. –2004. –
10. Интернет-ресурслар.

# ӘДӘБИ ӘСӘРНЕ ӨЙРӘНГӘНДӘ КОНЦЕПТУАЛЬЛӘШТЕРҮ ТЕХНОЛОГИЯСЕ

**Сафина Римма Ришат кызы**
*Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Сибгат Хәким исемендәге Күлле Киме төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Тема:** Әдәби әсәрне өйрәнгәндә концептуальләштерү технологиясен куллану алымнарын һәм формаларын күрсәтү

**Максат**: заманча белем бирү технологияләрен куллану техникасын тәкъдим итү

**Бурыч**:

1. Һади Такташның «Ак чәчәкләр ява» әсәре нигезендә концептуальләштерү технологиясен турыдан-туры һәм шәрехләнгән юл белән аңлату.
2. Технологиянең алымнарын бергәләп эшләү;
3. Субъект буларак мастер-класста катнашучыларның һөнәри осталыкларын үстерү.

**Мастер-классның технологик картасы**

| Мастер-класс этаплары | Эшчәнлекнең төре, формасы, алымы | Методик нигезләнү | Вакыт |
|---|---|---|---|
| 1. Оештыру – әзерлек этабы | Укытучының кереш сүзе | Конкрет эшчәнлектә мотивация һәм танып-белү ихтыяҗын формалаштыруны тәэмин итү | 1 мин |
| | Төркемнәргә бүлү (фокус-группа)<br>Максат һәм бурычларны кую. (аудиал, визуал, кинестетик) | Мастер-класс барышында катнашучыларның көтелгән фаразларын ачыклау | 2 мин |
| 2. Һади Такташның «Ак чәчәкләр ява» әсәре аша технологияне тәкъдим итү | Традицион, актив һәм интерактив укыту методларының асылын билгеләү | Мастер-класста катнашучылар алдына проблема кую | 3 мин |
| | Төсләр ассоцияциясе (презентация) | Мастер-класста катнашучыларның белемнәрен актуальләштерү | 2 мин |
| | Проблемалы ситуация | Мастер-класста катнашучыларның проблеманы сеңдерүе | 3 мин |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. Модельләштерү | Мини-проект. Фокус – группаларның проектларын яклавы (аудиал, визуал, кине-стетик) | Проект методының эле-ментларын куллану | 7 мин |
| 4. Рефлексия | Семинарда катнашучыларның һәркайсы мастер-класстан көтелгән фаразларны тор-мышка ашыру дәрәҗәсен анализлау | Мастер-класска нәтиҗә ясау | 2 мин |
| 5. Нәтиҗә | | | 20 мин |

**Йомгаклау өлеше**

Әдәбиятта әсәрне анализлау өчен концептуальләштерү технологиясе ни дәрәҗәдә отышлы, мин шуны раслыйсым килде. Мастер классны бу сүзләр белән тәмамласым килә. Укытучының асылы бу сүзләрдә:

Бу дөньяга без чиста булып киләбез. Язмыш үзенең төзәтмәләрен кертә. Ак бит. Ул әлегә чиста. Әмма барыбер анда нәрсә дә булса, саннар-мы, сүзләрме, рәсемме ясалачак. Ничек язылуы мөһим түгел, ә кем язуы һәм нәрсә язуы мөһим. Бала күңеленә язучы- УКЫТУЧЫ. Ә ул – чиста күңелле кешеме, яки....

Без,
Ак кәгазьдәй бала күңеленә,
Язмышларны башлап язучы.
Өмет тулы күпме күзләргә без
Яшәү чаткылары салучы.
«Ак биттән» дип аталучы язылмаган китабым – шул хакта

## ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕКНЕ ОЕШТЫРГАНДА ЛЭПБУК АЛЫМЫНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

**Фазулова Гөлнара Илдусовна**
*Чистай муниципаль районы*
*«Мөслим урта гомуми белем мәктәбе»*
*Югары квалификацион категорияле*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Туган тел һәм әдәбиятны укытуның сыйфатын күтәрүдә дәрестән тыш эшчәнлекне дөрес оештыру мөһим. Килеп туган ситуациядә дәрестән тыш эшчәнлекне урынлы һәм файдалы итеп куллану зарур. Безгә,

татар теле укытучыларына, сәгатьләр саны азайды дип, кул кушырып утырырга, төшенкелеккә бирелергә ярамый, туган телебезгә өйрәтүне, әдәбиятыбыз, сәнгатебезгә мәхәббәт уятуны дәрестән тыш эшчәнлек аша дәвам итәргә кирәк.

Федераль дәүләт белем стандартлары бездән туган илнең лаеклы гражданинын тәрбияләүне сорый, ләкин үз халкының тарихын, мәдәниятен, телен белмәгән баладан лаеклы гражданин тәрбияләү мөмкин түгел.

Нәрсә ул дәрестән соң эшчәнлек? Дәрестә уку эшчәнлегеннән кала укучыларны тәрбияләү һәм социальләштерү максатына юнәлдерелгән барлык эш төрләре дәрестән тыш эшчәнлек дип атала. Аны оештыруның төп максаты – укучыларның кызыксынуларын, сәләтләрен һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек шартлар тудыру һәм аларның буш вакытларын дөрес оештыру, шуның нигезендә тәрбияләү һәм тормышка әзерләү максатына ирешү.

Дәрестән тыш эшләр максатчанлык, фәннилек, системалылык, эзлеклелек, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу, балаларның мөстәкыйльлелеге һәм иҗади активлыгы, тормыш белән бәйлелек кебек гомумдидактик принципларга нигезләнеп оештырылырга тиеш.

Укучыларның иҗади активлыгын арттыру, фәнемә кызыксыну уяту, нәкъ менә минем фән буенча оештырылган дәрестән тышэшчәнлек юнәлешен сайлау өчен, мин үз эшемдә өр-яңа, кызыклы методик куллан-ма – лэпбук файдалана башладым. Аны дәрестә дә, дәрестән тыш чара-ларда да, өйдә файдаланырга мөмкин. Кызыклы материалларны тупла-ганда эти – әниләрне дә тартырга була.

**Нәрсә соң ул «Лэпбук»?** Лэпбук ул – интерактив тематик папка. Яки кулдан ясалган кесәле, ачыла торган матур китап. Аны беренче мәртәбә Америкада кулланганнар. Инглиз теленнән тәрҗемәсе(lap-колени,book-книга, «наколенная книга») җыелма күрсәтмә һәм таратма материаллар тупланган китап. Лэпбук ясаганда билгеле бер тема нигезендә эшләргә кирәк.

Лэпбук –рәсемле китап кына түгел, проект өстендә эшләү өчен ярдәмлек ул.

**Лэпбук нәрсә өчен кирәк**

1. Ул укучыга өйрәткән теманы яхшырак аңлау һәм истә калдыру өчен кирәк

2. Үткәнне кабатлау өчен бик яхшы алым

3. Өйрәнелгән материалны системага салып ныгытып куярга булыша

4. Укучы мәгълүматны тупларга һәм җыярга өйрәнә

5. Укучының сөйләмен, фикерләү сәләтен устерэ.

6. Эшләү дәверендә күзәтүчәнлекне арттырырга, чагыштырырга, анализ ясарга, гомумиләштерергә һәм нәтиҗә ясарга тиеш.

**Лэпбук нәрсәдән тора**

папкалар, кесәләр, китапчыклар һәм мәгълүмәтләр җыелмасыннан.

**Лэпбук ясау өчен кирәк материаллар:**

1. Җирлек өчен каты яхшы картон
2. Кайчы, клей, карандаш
3. Төсле карандашлар, фломастер, төрле төстәге ручкалар
4. Скотч
5. Фантазия.
6. Шаблоннар
7. Степлер

**План**

Лэпбук ясаганда билгеле бер тема нигезендә эшләргә кирәк. Шушы теманы ачу максатыннан план төзелә. Укучыларга сорау куела:

син нәрсә беләсең?

нәрсә беләргә теләр идең?

белү өчен нәрсә эшләр идең?

Белем һәм тәрбия бирүне берләштереп лэпбук укытучыга үз эшчәнлеген һәр баланың шәхси үзенчәлекләреннән чыгып төзергә ярдәм итә, ә балага үзбелем үстерүдә активлык күрсәтергә шартлар тудыра.

Дәрестән тыш эшчәнлекне оештырганда лепбук алымын куллану – тикшеренү эшен башкаруның (күзәтүләр яки тәҗрибәләр үткәрү һәм рәсем ясау) менә дигән ысулы, аның барышында укучы өйрәнелгән материалны ныгытачак һәм системалаштырачак, ә папканы карау алга таба үткән темаларны тиз арада хәтердә яктыртырга мөмкинлек бирәчәк. Бу проект яки тематик атна нәтиҗәләрен тәкъдим итү формасы да булырга мөмкин. Моннан тыш, ата-аналар җәмгыятен балалар һәм өлкәннәрнең уртак хезмәттәшлегенә һәм белем бирү процессына җәлеп итәргә мөмкинлек бирүче яхшы форма.

# PADLET.COM – ДИСТАНЦИОН УКЫТУНЫҢ БЕР ЧАРАСЫ

**Шаева Венера Мнахир кызы**
*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы*
*Татар Шураны төп гомуми белем бирү мәктәбе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

